НӘРСӘ ЭЧӘБЕЗ?

«ВТ» хәбәрчесе Казандагы суның сыйфатын ачыклады

> 7



ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ

Тормышны үзгәртү өчен сан һәм картага гына карау җитәме?

> 15

АЛСУ ГАЙНУЛЛИНА:

«Минем өчен гаилә һәрвакыт беренче урында булды»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 4 (28971) | Җомга | 13 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТОРМЫШ БӘЯСЕ

ЯҢА ТАРИФЛАР ХАЛЫКНЫ ПОШАМАНГА САЛДЫ

Көн кадагындагы мәзәк: «Коммуналь түләү кәгазьләренә караганда, хәзер краннан чишмә суы ага, ә чүпне «Лексус» машинасында чыгаралар...» Тик моңа көләргә дә, еларга да белмәссең. Ел башы «тешли» торган коммуналь түләү кәгазьләре белән истә калыр, мөгаен. Тик бу көтмәгәндә килеп чыккан хәл түгел. Ут-суга бәяләр артачагы турында быелтыр ук кисәттеләр. Белгечләр хис белән түгел, ә акыл белән эш итәргә куша. Декабрь өчен коммуналь түләү кәгазен «ВТ» хәбәрчесе дә җентекләп өйрәнде.

> 5

Ишетми калмагыз

Узган елның гыйнварыннан ноябрьгә кадәр Татарстанның нефть эшкәртү компанияләре 2,6 миллион тоннадан артыграк бензин эшләп чыгарган. Бу – алдагы елдагыга караганда 43 процентка күбрәк. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, дизель ягулыгын җитештерү 10,3 миллион тоннага җиткән.
Тулаем алганда, Татарстанда шушы чорда барлыгы 20,4 миллион тонна нефть (2021 елның шушы ук чорындагыга караганда 13 процентка күбрәк) эшкәртелгән.

Былтыр Россиядә сатылган транспорт саны алдагы ел белән чагыштырганда 55 процентка кимегән. Бу хакта «Автостат» аналитика агентлыгының башкарма директоры Сергей Удалов әйткән. Җиңел автомобильләр – 59, җиңел коммерция транспорты – 48, йөк машиналары – 16, автобуслар исә 7 процентка азрак сатылган.

Казанның Идел буе районындагы 2 нче Газ урамы атаклы эшмәкәр һәм Татарстаннан Дәүләт Думасы депутаты булган Айрат Хәйруллин исемен йөртәчәк. Урамдагы йортларның адрес номерлары сакланып кала. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гаффаров бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган. Карар шәһәр документлары һәм хокукый актларының махсус чыгарылышында басылып чыккан.
Айрат Хәйруллинның гомере 2020 елның 7 февралендә вертолет һәлакәтендә өзелде. Аңа 49 яшь иде.

Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марат Сафиуллин «Рубин» футбол клубының президенты итеп билгеләнде. Бу хакта Казан клубының матбугат хезмәте хәбәр итте. Директор вазыйфасын күп еллар «Ак барс»та эшләгән Шамил Хөснетдинов башкарачак. Моңа кадәр генераль директор булып эшләгән Рөстәм Сәйманов исә клубтан китте. Билгеле булганча, узган ел Казан командасы үз тарихында тәүге мәртәбә премьер-лигадан төшеп калды. Декабрьдә исә баш тренер Леонид Слуцкий да вазыйфасыннан китте, аның урынына Юрий Уткульбаевны билгеләделәр.

Зәмһәрир суыклар чигенә. Ял көннәрендә Татарстанда көндез –14, төнлә –19 градус көтелә. Республика Гидрометеоүзәге мәгълүматларына караганда, якын араларда Татарстанда явым-төшем көтелми. Шимбә, якшәмбе – 14–15 гыйнварда термометрның терекөмеш баганасы көндез –8...–14, төнлә –12...–19 градус күрсәтәчәк. Киләсе атна башында һава температурасының көндез –7...–12, төнлә –12...–17 градус чикләрендә тирбәлүе фаразлана.
Республикада гыйнварның беренче декадасында тәүлеклек уртача температура нормадан 13–23 градуска кимрәк булган. Атна башында – 9 һәм 10 гыйнварда Баулы, Мөслим метеостанцияләрендә һава температурасының 40 градустан түбәнрәк төшүе теркәлгән.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Яңа ел яллары вакытында Түбән Каманың бала тудыру йортында 48 сабый – 25 кыз һәм 23 малай туган. Бу хакта перинаталь үзәк һәм балалар хастаханәсендә хәбәр иттеләр. Ике гаиләдә игезәкләр туган. «Без яшь әти-әниләрне шундый күңелле Яңа ел бүләкләре белән котлыйбыз! Зур, көчле һәм бәхетле булып үсегез», – дип теләде табиблар.
(«Татар life»)

Саба

Түбән Утар авылы янында 10 гыйнварда «Бранко Рус» җәмгыяте төзегән күркә инкубаторы ачылды. Инкубатор беренче этапта айга 116 мең йомыркадан күркә чыгаруга исәпләнгән. Алга таба җитештерүне ике тапкыр арттырырга һәм ана күркәләр тоту өчен 6 ферма төзергә ниятлиләр. Инкубатор 29 кешегә эш урыны бирер дип көтелә, ә фермалар төзелгәч, бу сан 150гә кадәр җитәчәк. «Түбән Утарда заманча инкубаторның эшли башлавы җитештерүчеләр эшчәнлегенә уңай йогынты ясарга тиеш», – диде авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров.
(«Саба таңнары»)

Әлмәт

Әлмәт табибы Кирилл Булатов Лисичанскида булып кайтты. Анда ул 22 ноябрьдә үк киткән иде. Шушы вакыт аралыгында балалар хирургы булып эшләүче табиб 1200 баланы карарга өлгергән, көненә уртача 85 пациент кабул иткән. Кирилл Булатов Лисичанскидагы күпчелек балаларның физик яктан сәламәт булуын әйтә. «Төп проблема – балаларның психологик халәте: атышлар, бомбага тоту нәтиҗәсендә неврологик тайпылышлар башланган. Мин үзем анда булдым, янәшәдә шартлау тавышлары еш ишетелә. Балалар мондый шартларда инде ярты елга якын яшиләр», – ди ул. Авыруларны кабул итү кыр шартларында диярлек башкарылган. Шәһәрдә электр юк. «Мин кабул итүне шәһәрдә калган бердәнбер үзәк поликлиникада башладым. Аннан төрле мәктәпләрдә булдым. Балалар атнага бер тапкыр 20 минутка мәктәпкә баралар. Анда аларга өй эшләре бирәләр. Мәктәпләрдә, пушка куеп, бүлмәләрне бераз булса да җылыта алалар. Шуңа күрә балалар белән шунда очраштык».
(«Әлмәт таңнары»)

Зәй

Зәйдә шимбә ярминкәләре иртән үк эшли башлый һәм аларда шәһәр халкы ит, казылык, сөт, май, йомырка, бал, шикәр комы, ярмалар һәм башка фермерлык продукциясе сатып ала алалар. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Розалия Архипова хәбәр итүенчә, 2022 елда барлыгы 33 ярминкә уздырылып, анда 35 миллион сумнан артык продукция сатылган. Ә 2023 елда беренче авыл хуҗалыгы ярминкәсе бу шимбәдә – 14 гыйнварда оештырылачак.
(«Зәй офыклары»)

СУДА һӘМ КҮКТӘ

«Дельфин» йөздерәчәк, «Альбатрос» очачак. Президент Рөстәм Миңнеханов «Алабуга» махсус икътисадый зонасына эшлекле сәфәр кылды. Республика җитәкчесе утырышта да катнашты, биредәге эшләр белән дә танышты.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасында узган Күзәтчеләр советы утырышында 2 проект хупланды. Аның берсе – моторлы көймәләр җитештерү, икенчесе пилотсыз очу аппаратларына бәйле. «Дельфин Алабуга» җәмгыяте моторлы көймәләр җитештерүгә алынмакчы. Көймәләр корпусын, махсус ысул кулланып, углерод һәм пыяла тукымалар нигезендә композицион материалдан ясау күздә тотыла. Гади материаллар белән чагыштырганда, болары ныграк та, җиңелрәк тә. Көймәләрне чит илгә сатарга ниятлиләр.

«Альбатрос» компаниясе исә пилотсыз очу аппаратлары җитештерәчәк. Бу эш белән алар 2017 елдан бирле шөгыльләнә. Мөмкинлекләрен зурайтып, 400гә кадәр яңа эш урыны булдырырга телиләр. Әлеге очкычларны урман янгыннарын күзәтү, продукция китерү, авыл хуҗалыгы, саклау һәм күзәтү өчен, күңел ачу юнәлешендә һәм фән өлкәсендә кулланып булачак. Киләчәктә елына 1 меңгә кадәр пилотсыз очу аппараты җитештерү планлаштырыла.

Президент «Алабуга»да гамәли укыту үзәген дә карады. Проектның төп максаты – «Алабуга-Политех» мәгариф үзәге студентларын заманча алымнар белән эшләргә өйрәтү.

РОССИЯ МАТБУГАТЫ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия матбугаты көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле журналистлар, нәширләр, газета һәм журнал редакцияләрендә эшләүчеләр, полиграфистлар, ветераннар һәм яшь каләм әһелләре, барлык басма һәм цифрлы мәгълүматны әзерләү, бастыру һәм тарату белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез – Россия матбугаты көне белән котлыйм!

Тарихта калган ел кыен булды, ул безне күп кенә әйберләргә башкача карарга өйрәтте. Шушы гади булмаган шартларда республика массакүләм мәгълүмат чаралары һөнәри осталыкларын һәм җәмгыять алдында җаваплы булуларын тагын бер мәртәбә күрсәтте. Шуңа күрә дә Татарстанның журналистлар җәмәгатьчелеге Россиядә иң көчлеләрдән санала, аның нык традицияләре һәм үз һөнәри мәктәбе бар. Татарстан Республикасының хакимият һәм идарә органнары сезнең хезмәтегезне югары бәяли һәм нәтиҗәле сөйләшү өчен һәрвакыт ачык булырга омтыла. Шулай эшләсәк кенә, без уңай мәгълүмат дөньясын һәм халык белән җанлы элемтә булдыра алачакбыз.

Нинди генә шартларга да карамастан, илебезнең күпмилләтле халкының һәрвакыт бергә һәм бердәм булуы, авыр вакытта ярдәм кулы сузарга ашкынып торуы горурланырлык. Бу үзгәрмәс сыйфатлар – илнең мәдәни нигезе. Граждан тынычлыгы һәм милләтара татулыкның ныклыгы күп очракта республика журналистларының иҗади эшенә, гаделлегенә, тегe яисә бу теманы тирәнтен белүенә һәм һәрьяклап үлчәнгән карашына бәйле. Массакүләм мәгълүмат чаралары агымдагы хәлләрне тасвирлап кына калмый, ә вакыйгалар агышына куәтле йогынты да ясый, һәм, бу җәһәттән, бүгенге көн кадагындагы мәсьәлә булган ватанпәрвәрлекне һәм халкыбызның традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен алга таба да актив яктыртуыгызга ышанабыз. Бүген бу мәсьәләләр иң беренчел әһәмияткә ия һәм 2023 елны Россия Федерациясендә Укытучы һәм остаз елы, Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы итеп игълан итү һич кенә дә очраклы хәл түгел.

Кадерле дуслар! Бәйрәм көнегездә җәмгыять һәм дәүләт алдында торган авыр, кайвакыт каршылыклы мәсьәләләрне хәл итүдә актив катнашуыгыз, сезнең нәтиҗәле хезмәттәшлегегез өчен ихлас рәхмәт сүзләрен белдерәм. Сезгә иҗади куәт, яңа идеяләр һәм кызыклы проектлар, илһам чишмәгезнең саекмавын, үзегезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, бәхет, тынычлык һәм иминлек телим!

ЯТ КЕШЕ ТҮГЕЛ

Татарстан яшьләре ике көн генә министрсыз яшәде. Дүшәмбе Тимур Сөләймановтан бушаган урынга Ринат Садыйковны билгеләү турындагы указ чәршәмбедә чыкты.

Инде хәбәр иткәнебезчә, Тимур Сөләйманов Татарстан Президенты ярдәмчесе итеп билгеләнде. Ул Бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең республика бүлеге җитәкчесе вазыйфасын да башкарачак.

Яңа җитәкчене хезмәт коллективына Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин тәкъдим итте. «Ринат Садыйков ят кеше түгел. Коллектив эчендә хәрәкәт булуны һәм эш юнәлешләренең үзгәрмәвен бик дөрес дип саныйм», – диде Премьер-министр. Ул Ринат Садыйковның капиталь ремонт, яшь гаиләләргә ярдәм программалары, балаларның җәйге ялын оештыру кебек тармакларда-гы эшен дә югары бәяләде. Яңа министр студентлар хезмәт отрядлары аша да бик яхшы таныш.

Ринат Садыйков **1986 елда** Казанда туган.
- **2008–2018 еллар** – студент хезмәт отрядларының республика хәрәкәте җитәкчесе.
- **2018–2021 еллар** – Татарстан яшьләр эшләре министры урынбасары.
- **2021–2022 еллар** – Татарстан яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары.
- **2022 елның феврален**нән – Татарстан яшьләр эшләре министры.

– Моңа кадәр яшьләр сәясәте командасы тарафыннан республикада яшәүче егетләр һәм кызлар үз проектларын тормышка ашырсын, укысын, тырышып эшләсен һәм яшәү өчен иң яхшы урын дип Татарстанны сайласын өчен бик күп эш башкарылды. Республика җитәкчелеге тарафыннан яшьләр сәясәтенә зур әһәмият бирелә, бу безгә алга таба да уңышлы рәвештә алга бару мөмкинлеген тәэмин итәчәк, – диде яңа министр.

Аңа Тимур Сөләйманов та уңышлар теләде.

– Ринат Садыйковны бик күптәннән, студентлар хезмәт отрядларында эшләгән чактан ук беләм. Ул – үз эшенең чын остасы, ышанычлы, җаваплы һәм хезмәт сөючән кеше. Аның министр булу өчен бөтен кирәкле сыйфатлары бар. Шуңа күрә тармак алдында торган бурычларны хәл итә алуына да шигем юк. Яшьләр сәясәте әле барып җитәргә өлгермәгән юнәлешләргә игътибарны арттырырга кирәк, – диде Президент ярдәмчесе. Үзе җитәкләгән хәрәкәт һәм Яшьләр министрлыгы бер-берсен көчәйтеп торачагына да ышаныч белдерде ул.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Мортаза Рәхимов вафат булу сәбәпле, Башкортстан башлыгы Радий Хәбировка кайгы уртаклашу телеграммасы җибәрде.

«Татарстанда яшәүчеләр, шәхсән үз исемемнән, Башкортстанның Беренче Президенты Мортаза Гобәйдулла улы Рәхимовның вафат булуы сәбәпле, кайгыгызны уртаклашам. Исеме башкорт халкы тарихының тулы бер дәверенә бәйле зур шәхес, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм абруйлы җитәкче арабыздан мәңгегә китте. Ул иң катлаулы үзгәрешләр чорында республикага җитәкчелек итеп, туып-үскән төбәгенең язмышы өчен авыр җаваплылык йөген кыю төстә үз өстенә алды. Бик тирән сәяси, икътисадый һәм социаль үзгәртеп коруларны хәл итү өчен иҗтимагый көчләрне туплауга, төбәкне төрле яклап үстерүгә, Башкортстанның күпмилләтле җирендә тынычлык-татулыкны саклауга иреште. Белеме һәм тәҗрибәсе, рухи көче, яңаны булдыру юлындагы тырышлыгы соңгы көннәренә кадәр үз республикасы һәм халкы файдасына эшләде. Башкортстанның тугандаш халкының олы кайгысын әчкерсез уртаклашабыз, Мортаза Гобәйдулла улының хатыны Луиза Галим кызына, барлык туганнары һәм якыннарына сабырлык телибез. Мәрхүмнең авыр туфрагы җиңел, мәңгелек йокысы тыныч, урыны җәннәт түрендә булсын», – диелә телеграммада.

Кайгы уртаклашу сүзләрен Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, Беренче Президент Минтимер Шәймиев һәм Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да җиткерде. «Мин Мортаза Гобәйдулла улына күпьеллык нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәтлемен, безне үзара эшлекле, шул ук вакытта халыкларыбыз арасында кебек үк дуслык, тугандаш мөнәсәбәтләр дә бәйләде», – диелә Минтимер Шәймиев телеграммасында. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Мортаза Рәхимовның озак еллар дәвамындагы күпкырлы эшчәнлеге Башкортстан һәм Россия Федерациясенең яңа сәяси, хокукый системасын булдыруга, милләтара тынычлык-татулыкны ныгыту, ике республиканың тугандаш халыклары арасында төрле яклы элемтәләрне үстерүгә бәйле булды.

Мортаза Рәхимов 11 гыйнварда вафат булды. Аңа 88 яшь иде. Башкортстан Президенты вазыйфасын ул 1993–2010 елларда башкарды. Аннан соң «Урал» хәйрия фонды белән идарә итте.

ЭШ ТӘ БАР, ЯРДӘМ ДӘ

Эшлим дигән кешегә эш җитәрлек. Татарстанда бер эшсезгә 5,5 вакансия бар. Бала үстерүчеләргә дәүләттән ярдәм чаралары җитәрлек. Бу яктан Россиядә безгә тиңнәр юк икән. Соңгы ун ел эчендә гаиләдә өченче сабый туу күрсәткече 70 процентка артып, аларның саны 24 меңнән 42 меңгә җиткән.

Бу хакта узган елга нәтиҗә ясап үткәрелгән киңәйтелгән утырышта Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сөйләде.

– Татарстанда ел башында тулы көн эшләмәүчеләр 18 меңгә җиткән иде. Бу ковид чорындагы чикләүләргә бәйле булды. Санкцияләр дә үз эшен эшләде. Шул сәбәпле, күп кенә оешмаларда эшләүчеләр кыскартылуга эләкте. Әмма эшсезлекне көйли алдык. Хәзер эшсезләр саны 7,5 меңгә калды, – диде министр. – «Демография» илкүләм проекты кысасында 2,5 меңнән артык кеше маркетплейсларда эшләргә өйрәнде. Шунысы сөенечле, ул кешеләр үз эшләрен ачып, шәхси эшмәкәрләр һәм үзмәшгульләр булып теркәлде. Әмма әле дә Чаллы, Алабугада эшче куллар җитми. Анда урнашкан оешмаларга 12 мең эшче кирәк.

Эшсезлекне бетерү өчен 30 яшькә җитмәгән, эш таба алмаган, кыскарту алдында торган кешеләргә дәүләт эш субсидиясе бирә башлаган. Алар эшкә урнашкан очракта, дәүләт өч яшәү минимумы күләмендә акча бирә. Кеше аның беренчесен – эшкә кереп бер ай узгач, икенчесен – 3 айдан, өченчесен алты айдан ала. 30 яшькә кадәрге 1,6 мең яшь белгечне эшкә урнаштырган 732 предприятие федераль бюджеттан субсидия алган. 12,5 мең татарстанлы, шул исәптән 4,5 мең эшсез кеше, ихтыяҗ зур булган белгечлекләр буенча белем алырга өлгергән.

Министр хәрби операциядә катнашучы ир-атларның гаиләләренә күрсәтелә торган ярдәмнәргә дә тукталды. Республикадагы һәр гаиләгә ярдәмче беркетелгән.

Эльмира Зарипова республикада бала үстерүче гаиләләргә аеруча зур әһәмият бирелүен дә искә төшерде. Бердәм пособие хакында да сүз булды. Аңа керемнәре яшәү минимумыннан ким булган гаиләләр өметләнә ала. Кыскасы, үз эченә алты төр ярдәмне керткән бу пособие бала ана карынында чакта ук түләнә башлап, аңа 18 яшь тулганчы дәвам итә ала.

Имин булмаган гаиләләргә ярдәм чаралары турында Эльмира Зарипова күп тапкыр сөйләгән иде инде. Авыр хәлдә яшәүче гаиләләргә социаль контракт ярдәмгә килә. Дәүләт андыйларга, үз эшен башларга дип, акча бирә. Ул акчаны кайтарасы булмый. Бер генә шарт: аз керемле булган гаиләнең кулында нинди эш башлаячагы турында бизнес планы булырга тиеш. Шәхси эшмәкәрлеккә керешүчеләргә бер тапкыр 350 мең сум, үз хуҗалыгында маллар тотучыларга 200 мең сумга кадәр ярдәм каралган. 2022 елга кадәр авыл җирендә яшәүче авыр хәлле гаиләләр социаль контракт төзи алмаган. Сәбәбе – мохтаҗлыкны исәпләгәндә пай җирләре булу комачау иткән. Хәзер аны исәпкә алмый башлаганнар.

Утырышта Мәскәү кунагы, Россия хезмәт һәм социаль яклау министры урынбасары Андрей Пудов та катнашты. Ул Татарстанны бар яктан үрнәк дип атады. Республикада күпбалалы гаиләләрнең артуын да билгеләп китте. Татарстанда бирелә башлаган «Ата-ана фидакарьлеге» медале турында да искәртте.

– Татарстан – пилот проектларда катнашырга курыкмый торган төбәк. Кадрлар җиту, белгечләрегез булу белән аңлатыла бу. Пенсия фонды белән Социаль иминияләштерү фондын берләштерү дә сездән башлана. Без инде бүген үк моның уңай якларын күрдек. Димәк, сез дөрес юлда, – ди ул.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин икътисадый яктан катлаулы елда да үз эшләрен югары дәрәҗәдә алып барулары өчен социаль тармак хезмәткәрләренә рәхмәтен җиткерде.

– Хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтүне дәвам итәбез. Бу гаиләләрнең социаль паспорты булырга тиеш, – ди Рөстәм Нигъмәтуллин. – Оешмаларда тулы эш көне эшләмәүчеләрне дә ачыкларга кирәк. Сәбәпләре нидә? Хәзер безгә эш урыннарында кирәкле һөнәрләрне кайгырту мөһим. Хезмәт хакларына килгәндә, яшәү минимумыннан түбән акча түләүчеләр дә контрольдә булырга тиеш. Бергә эшләгәндә генә нәтиҗә булачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сәяси сәгать

АЛЬБЕРТ ШАКИРОВ:

«Күңел җылынсын өчен тамак тук булу кирәк»

Без әле кая барабыз? Дөньяда ниләр бар? Бу сорауларга җавапны журналист, блогер Альберт ШАКИРОВ белән эзлибез.

:: Өлешчә мобилизация башлангач, чит илгә чыгып киткән ир-егетләр турында әледән-әле искә алып торалар. Берәүләр аларны кире кертмәскә, икенчеләр, кайткан очракта да, эш бирмәскә тәкъдим итә. Чикләрне ябып, мондагыларны чыгармау турындагы сүзләр Кремль дәрәҗәсендә кире кагылды. Әмма имеш-мимешләр бетми. Мондый хәбәрләр ир-ат халкының тынычлыгын юкка чыгара түгелме?

– Тынычлыкны юкка чыгара дип әйтә алмыйм. Ә менә ачуны китерә. Бигрәк тә Дәүләт Думасы тирәсендәге кешеләрнең кирәкмәгән тәкъдимнәр белән шөгыльләнеп ятулары. Бу инде җил кайсы якка иссә, бездән дә өлеш булсын дип, шул якка өрергә тырышу, үзләрен күрсәтергә маташулары. Гомумән, Украинадагы хәлләр тирәсендә үзләренә исем ясарга маташучылар җитәрлек. Бу хакта нидер әйткәч, барыбер игътибар итәселәре, ниндидер кайтаваз буласы, күпмедер вакыт кабатлап сөйлиселәре билгеле. Шуңа күрә үзләреннән, кем әйтмешли, өч тиен кыстырырга тырышалар. Ләкин араларында ачыктан-ачык провокация буларак бәяләнерлек сүзләр дә бар. Ярым-йорты мондый хәбәрләрнең эченәрәк кереп, игътибар белән карый башласаң, берниндиэһәмияте юклыгын күрәсең. Шуңа күрә борчылырга урын юк.

Читкә чыгып киткән егетләргә килгәндә, аларга кагылышлы закон кабул ителгән очракта да, аны ничек эшләтәсең? Бар кешене дә бер чыбыктан сөреп булмый бит. Әйтик, кешенең качып чыгып киткәнен ничек исбат итәсең? Шуңа күрә мондый сөйләшүләрне буш дип саныйм. Депутат түгел, гафу итегез, кухняда салып утырган кеше сүзенә охшап кала мондый сүзләр. Ярый, кире кертмәделәр ди, безгә бит эшче куллар кирәк. Шул ук IT белгечләр урынына алмашка кеше әзерләгәнче кимендә 5–6 ел вакыт кирәк. Кайда нишләп йөрсә дә, икътисадка әзер белгеч ул. Ачыктан-ачык каршы фикерләр әйтмәгән икән, андый кешеләрне кире кагып, борып җибәрүне дөрес дип санамыйм.

:: Үзебезгә әйләнеп кайтсак, бу көннәрдә җанисәп нәтиҗәләре ачыкланды. Татарстанда халык саны артуга сөендек. Димәк, бездәге тормыш начар түгел икән. Әмма татарлар саны кимү борчуга салды, гаҗәпләндерде дә. Әллә бу гаҗәп түгелме?

– 10 ел эчендә 600 мең чамасы кешегә кимү – куркыта торган сан. Алай ук булыр дип уйламаган идем. Бу бит инде демографиягә бәйле вазгыять кенә түгел. Милләт төшенчәсе икенче планга күчә, ахрысы. Глобализациянең дулкыннары безгә дә бәрә башлады. Соңгы вакытта шулай дип уйлый башладым. Бигрәк тә чит төбәкләрдә яшәүче татарлар ассимиляциягә дучар була. Күчеп киткән кешеләрнең балалары, оныклары үзләрен татар дип санамаска мөмкин. Сәбәп шунда икән, бу сан алга таба да үсәчәк. Татарстанда миллилеккә катнашы булган, әйтик, педагогика, мәдәният-сәнгать юнәлеше буенча белем бирүче укытучылар белән сөйләшкәндә алар да әйтә: соңгы елларда яшьләр, студентлар арасында милли үзаң кими. Бу яшьләр инде башкача фикер йөртә. Шуңа күрә татарлар саны кимү гаҗәп түгел, әмма куркыныч. Ничек итеп үзгәртеп буласын әйтә алмыйм. Чөнки безгә генә хас күренеш түгел. Башка илләрдә дә, әйтик, шул ук АКШта да барлык милләтләрнең бергә буталып, боткага әверелүе күзәтелә. Бәлкем, дәүләткә нәкъ шундый масса барлыкка килү кулайрактыр да. Милли республикаларга, телләрне өйрәнүгә бүгенге мөнәсәбәт тик торганнан гына барлыкка килми дип уйлыйм.

:: Җанисәп нәтиҗәләренең кышкы яллар вакытында игълан ителүе игътибарыңны җәлеп итмәдеме?

– Сәер булды. Бәлкем, бәхәсләр тынсын өчен махсус шулай эшләнгәндер.

:: Яллар димәктән, кышкы каникул ел буена җыелып килгән борчу-мәшәкатьләрдән, һич югы шул хисләрдән берәзга булса да арынырга ярдәм иттеме?

– Сүз дә юк, ярдәм итте. Халык бәйрәм чараларына бик теләп йөрде. Бигрәк тә Казанда. Ник дигәндә, соңгы еллардагы чикләүләр, борчу-мәшәкатьләр белән яшәү ялыктырды. Шуңа күрә чыгып, бераз җилләнеп керү, бетмәс-төкәнмәс күңелсез хәбәрләрдән арынып тору кирәк иде. Башны ял иттерергә мөмкинлек булды.

:: Еллардан соң бәргән салкыннарны ни өчендер гадәттән тыш хәл кебек кабул иттек. Халык нәзберекләнә бара дигән сүзме бу?

– Юк, нәзбереклек түгел. Уңайлы тормышка ияләнеп киттек. Бер көнне ярты сәгатькә утны өзәләр. Бик сәер тоелды. Андый хәлләр онытылып бара бит инде. Без хәзер салкынга ияләшмәгән. Авылда да җылытылган яңа йортларда яшибез. Утын ташуйсы, күмер ягасы юк. Шуңа күрә бу көннәрдә биш минут саен температураны карап тордык. Ләкин авыл җире өчен бик яхшы булды бу суыклар. Иң мөһиме – күңелләребез җылы булсын. Әмма анысы өчен дә тамак тук булу кирәк.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Әйтеп кенә бактым

Әти кызы

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Яңа ел алдыннан гына авырып китү бер дә җүнле нәрсә түгел инде ул. Бар халык Яңа ел каршыларга әзерләнә, ә мин, киләчәккә өмет күзе белән карап, сырхауханәдә ятарга мәҗбүр.

Дөрес, сырхауханәгә эләгүне бәхет дип кабул итәргә дә кирәктер. Чөнки миңа «двухсторонняя пневмония» дигән диагноз куйган табиб «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртырга киңәш итте, чөнки бүген төрле зәхмәтләр котырып, сырхауханәләр авырулар белән шыплап тулган һәм анда эләгү, гомумән, мөмкин эш түгел, ди. Ә «ашыгыч ярдәм» машинасы китергән авыруны кире борып җибәрә алмыйлар икән, табиб әйтмешли, «не имеют право». Менә шул, «тулы хокуклы» авыру булып, Риман абыегыз бүлнис бусагасын атлап керде. Әмма беренче ике көндә аның «хокук»ы коридорга куелган ятак белән чикләнде. Дөресен әйткәндә, бер генә дә борчылмадым, ни дисәң дә, язмышым ышанычлы кулларда бит. Аннан соң минем кебек аралашырга яраткан кеше өчен, коридор – бик кулай урын. Синең яныңнан, карык-корык йөткереп, көненә ничә кеше үтеп китә, бер-береңә сәлам биргән, хәл сорашкан буласың. Шулай итеп кайгы-шатлыклар уртакка әйләнә.

Ике көн узгач, мине палатага күчерделәр. Шулай итеп, «тулы хокуклы» авыруга әйләндем. Әмма ике урынлы палатада берүземә күңелсез иде. Укол кадарга кергән шәфкать туташларына: «Үземне генә калдырмагыз, ялгызлыктан куркам», – дип сүз каткан булам. Берсе тынычландырды: «Борчылма, бабай, синең янга тагын бер бабай кертәбез», – диде.

Биш минут вакыт узды микән, палатага бер бабай утырган коляска керттеләр. «Бабай» дигәнем минем корма кеше булып чыкты, ягъни җитмеш биш яшьләрдә. Кул биреп күрештек, Тәлгать исемле икән. Кызы озата килгән. Кечкенә генә, әмма бик җыйнак, матур гәүдәле, кара чәчле, зәңгәр күзле. Исеме – Ләйлә. Бүлмәдәшләремнең исемнәрен үзгәртмәдем. «ВТ»ны укучылар язганнарымны гыйбрәт итеп башкаларга сөйләрләр дип уйладым. Без ата-ана, бала арасындагы мөнәсәбәтләр турында күп сөйлибез, күп язабыз. Әмма шәхсән үземнең этисен Ләйлә кебек караучыларны очратканым булмады. Һәрхәлдә, хәтерләмим.

Тәлгать бик авырлык белән генә йөри, көнгә әллә ничә мәртәбә температурасы күтәрелә, кан басымы уйный. Шикәр авыруы булганлыктан, бик еш «тышка чыгасы» килә Тәлгатьнең. Кайчак аның бәдрәфкә барып җитә алмаячагын сизә Ләйлә һәм үзе алып килгән савытны куя. Тәлгать ояла, уңайсызлана, ә кызы: «Әти, монда чит кеше юк бит», – дип, аны тынычландырырга тырыша.

Мин сак кына Ләйләдән үзенең гаилә хәлен сорашам. Ире белән аерылышырга туры килгән икән аңа. Сәбәбен төпченеп тормадым. Әмма чамалыйм. Еллар буе авыру этисен караган хатын белән бөтен ирнең дә яшисе килмәс. Ләйлә этисе белән нинди сырхауханәләрдә булганын тезеп санап киткән иде. Сыкранып әйтмәде ул, әйтерсең лә этисе белән шифаханәләрдә ял иткәннәр. Курчак кебек кенә гәүдәле бу кызга каян килгән мондый көч, рух ныклыгы? Этисе кайвакыт: «Терелеп булмас, ахры, инде, кызым», – дип ыңгырашып куя. Ә Ләйлә: «Юкны сөйләмә әле, эти», – ди.

Тәлгатьне дә аңлыйм. Бер көнне футболкасын күтәреп, күкрәгеннән кендеккә хәтле сузылган җөйне күрсәтте. Йөрәгенең ике клапанын алмаштырганнар, бөерен алганнар икән. Ә Ләйләсе: «Борчылма, эти, яшибез әле», – дип, аның күңелен күтәрергә тырыша.

– Белмим инде, кызым, белмим…

– Ә мин беләм, эти.

Ата белән кызның сөйләшкәннәрен тыңлаган саен, Ләйләгә мәхәббәтем арта бара. Этисе хакына, үзе әйтмешли, «вакытлыча» эшен дә ташлаган икән ул. Кыскасы, шәхси тормышыннан ваз кичкән.

Без алар белән биш көн яшәдек. Мин Ләйләнең ятып бер йоклаганын да хәтерләмим. Аңа коридордан кушетка да кертеп куйган идек. Төнлә шунда ята гына, йә Тәлгать, йә мин йөткереп куябыз да, Ләйлә, сикереп торып, этисе янына килә. Башын тотып карый, юешләнгән киемнәрен алыштыра. Аннан соң песи кебек бөгәрләнеп, этисенең аяк очына ята. Монысы үзе ялгыш йоклап китмәсен өчендер дип уйлыйм инде. Чөнки кайчак Тәлгать урыныннан үзе торырга азаплана, бер-ике мәртәбә егылып төшә язганы бар. Сырхауханә ял йорты түгел шул. Авыруларның көне-төне ыңгырашуларын, саташып кычкыруларын тыңлап яту таза кешене дә авыруга сабыштырырга мөмкин. Ә курчак гәүдәле Ләйлә үзенең гамәлләре, сүзләре белән минем бөтен күңелсез уйларымны таратты. Классикларчарак әйтсәк, ул «караңгылык патшалыгында яктылык нуры» кебек иде. Бәлки, «үпкә ялкынсынуы» дигән зәхмәттән шулай тиз котыла алуым белән мин Ләйләгә бурычлыдыр да әле, дип уйлап куйдым.

Сеңлем, очраклы рәвештә тагын бер очрашырга насыйп булса, мин сине, кочаклап, бер үбәрмен әле, үз баламны үпкән кебек, дип әйтүем.

ШАХМАТ ТАКТАСЫНДА

Бу юлларның авторы үзе язган фаразларны онытмый, аларның күпмесе тормышка ашуын, күпмесенең кире кагылуын күзәтеп бара. Фаразлар исә, кызганыч, күп вакыт тормышка аша. Кызганыч дип шуңа әйтәм: начар фаразлар ясарга туры килә.

Әйтик, 2022 елның мартында: «Бу юлларның авторы якын көннәргә оптимистик фараз бирә алмый. Безнең барлык оптимизмыбыз бүгеннең иртәгәдән яхшырак булуын аңлауда гына. Март апрельгә караганда яхшырак, апрель – майга караганда», – дип язганмын. Газета хәбәрчесенең бу фаразын Тышкы разведка академиясендә белем алган, танылган разведчик һәм журналист генерал-майор Юрий Кобаладзе соңгы көннәрдә генә кабатлады: «2023 год будет хуже 2022 года, но лучше 2024 года. Это и есть оптимизм», – диде. Безнең фараз алдарак булгач, үзебезнең авторлык хокукын саклыйбыз инде.

Үткән фаразларга кайту безгә киләчәкне фаразларга булыша. Мәсәлән, менә «Быел, 2023 елда, безнең матди хәлебез ничегрәк булыр?» дигән сорауга төгәллеккә якын җавап табарга ярдәм итә. 2022 елда безнең тормышның матди дәрәҗәсе түбәнәйде, билгеле, әмма түзмәслек түгел. Россия – бик бай ил, шул байлыкны ипләп кенә тотсак, без күптән балда-майда йөзәр идек инде. Юк, без шөкер итәбез, әлбәттә, әмма мәгънәсезгә исраф ителгән байлыклар барыбер күңелне әрнетә. 2022 елда тышкы сәүдә профициты рекордлы булды, күп экспортладык – аз импортладык. Сәбәбе: дус булмаган илләр безнең чималны сатып ала, ә безгә үз товарларын сатуны чикли. Аларның чикләвенә хәтта дус саналган илләр дә бик еш кушыла. Стратегик чимал сатып, кулда бернигә дә ярамаган доллар һәм евролар тотып калырга туры килә. Валютаны читкә чыгарып кына файдаланып була, шул сәбәпле илдән капитал качу үткән ел рекордлы булды. Саннарны китереп тормыйбыз, максат башка.

Әйдәгез, сәясәтнең һәм икътисадның шахмат тактасында бер Кремль ягыннан, бер «дус булмаган» илләр ягыннан торып уйнап карыйбыз. Кремль позициясенә баскач, болайрак фикер йөртәбез һәм шуннан чыгып ат йөрешләре ясыйбыз: Көнбатыш безнең ресурсларга мохтаҗ, алардан башка бер адым да атлый алмый. Без нефть һәм газ сатмасак, энергия чыганакларына бәяләр күккә ашачак, бу финанс кризисы гына түгел, энергетик кризис та китереп чыгарачак һәм европалылар без урнаштырган уен кагыйдәләренә буйсыначак: бәяне, түләү шартларын Мәскәү куячак, шуңа өстәп, Көнбатышта Украинага хәрби һәм финанс ярдәмен дә туктатырга мәҗбүр булачаклар.

2022 елның мартында болай фикер йөртергә нигез җитәрлек иде шикелле. Шуннан чыгып, Кремль бөек ат йөреше ясады: газ өчен сум белән түләү турында указга имза салынды. Башта газ, аннан башка экспорт чималлары акрынлап сумнарга сатыла башларга тиеш һәм рубль башка резерв валюталары кебек үк конвертацияләнә торган валютага әвереләчәк. Американнар керткән барлык тиңе булмаган санкцияләр җимерелеп төшәчәк. Бу безгә, россиялеләргә, чит илләрдә үзебезне вәкарь белән тотарга юл ачачак, кесәдәге сумнарны җиңел генә үзебез килеп төшкән ил валютасына алыштырачакбыз, безгә хөрмәт белән караячаклар.

Фикер йөртүнең бу рәвешен газета хәбәрчесе указга имза салынганчы ук кире какты. Без валюталарның пьедесталга менү шартларын һәм тарихын белә идек чөнки. Мәскәүдә сул карашлы берничә икътисадчы бар, шулар Кремльне уйланып бетерелмәгән адымга этәрде. Махсус хәрби операция идеясе дә асылда шуларныкы иде. Без «Дус булмаган илләр» сумнарны кайдан алыр?» дигән язма әзерләдек һәм ул газета сайтына 24 мартта эленде. Әле указга имза салынырга бер атна бар иде. Без болай дип язганбыз: «Без әле монда сумга шикәр сатып алуда кыенлыклар кичерәбез, көнбатышлылар андый волатиль, ягъни курсы һәм кыйммәте уйнап торган акча белән эш итәргә теләмәс, билгеле. Икенче төрле әйтсәк, сумның дәрәҗәсен күтәрү өчен, Россиянең икътисадый куәте юк. Сәяси йогынтысы да чамалы гына… Газга бик мохтаҗ булганлыктан, Европа вакытлыча булса да сумнар белән түләргә риза булыр, бәлки. Бу бик уңышлы сценарий булыр иде. Гадәттән тыш уңышлы хәтта. Әмма АКШ, моңа юл куймас өчен, бар көченә тырышачак. Вазгыять менә шулай катлауланып үсә».

Үткәннәргә борылып карыйк. Безнең фараз йөз процентка тормышка ашты. Европага газ экспорты тукталды диярлек. Сатылган кадәресенә дә беркем дә сумнарда түләмәде. Россия тәкъдим иткән схема сумнарда түләүне үк карамый да иде. Ул импортерларга «Газпромбанк»та хисап ачып, валютаны шунда күчерүне генә таләп итте, банкирлар үзләре аны сумнарга әйләндерәчәк иде. Менә шундый зыянсыз гына схема да тормышка ашмады һәм Владимир Путин 2022 ел белән 2023 ел тоташкан мизгелдә яңа указ – көнбатышлыларга түләнмәгән әҗәтләрен валютада түләргә мөмкинлек бирә торган документка кул куйды. Хәзер бит проблема газны сумга сату түгел, гомумән, ничек сату дигән яссылыкка күчте. Европалылар без фаразлаганча туңмадылар да, бөлмәделәр дә, киресенчә, кыш уртасы булуга карамастан, газга бәяләр төшә. Көнбатышлылар кулында җәен кыйммәткә сатып алган газ бәясен Россиядән компенсацияләтү механизмы бар һәм алар шул механизмны эшкә җигә башлар, мөгаен.

Хәзер инде Брюссель позициясенә басып карыйк. Бер нәрсәне истә тотабыз: Көнбатышта үзләренә дошман булган илләрне тезләндерүнең бай тәҗрибәсе бар. Еллар узарга мөмкин, әмма нәтиҗәгә ирешелә. Дөрес, планетада вазгыять берникадәр үзгәрде: шахмат тактасында үз уен кагыйдәләрен кертергә омтылган илләр пәйда була башлады. Вәләкин Көнбатышның сәяси йогынтысы һаман да көчле, икътисадый куәте россиянекенә караганда чагыштыргысыз зур, хәрби яктан өстенлек тә бөтен дөньяда алар ягында. Моны танырга кирәк. Танымау катастрофага китерәчәк. АКШ һәм Европа берлегенең максаты мондый: Россияне икътисадый яктан тезләндерү, Украина конфликтын Мәскәү капитуляциясе белән төгәлләү. Аларның бер өстенлеге бар: конфликтта турыдан-туры катнашмыйлар, утлы күмерне украиннар кулы белән чүплиләр.

Шунысын да таныйк: 2022 елда көнбатышлылар икътисадый яктан тезләндерү максатына ирешә алмадылар. Бу – беренче максат, икенчесен дә шул тәэмин итә. Әмма максатка ирешүнең мөһим адымнары ясалды. Нефтькә чик бәя куелды һәм эшли башлады: Россия «кара алтын»ны чик бәядән күпкә арзангарак сатарга мәҗбүр. Сүз диңгез портлары аша сатыла торган җир мае турында гына бара, кагыйдә торба нефтенә кагылмый. Россия күп югалта, ләкин резервлары җитәрлек, бюджет дефицитлыга әйләнсә дә, социаль йөкләмәләр үтәләчәк, махсус хәрби операция өчен дә акча җитәчәк. Чик бәя билгеләүнең беренче нәтиҗәсе шул булды: доллар һәм евро кыйммәтләнде. Бюджет өчен монысы да файдага гына. Путин, Көнбатышка җавап итеп, яңа указ имзалады, ләкин аның бернинди дә тәэсире булмаячак, чөнки Көнбатыш диңгез портлары аша бездән нефть алмый.

Европалылар кулында көчлерәк һәм астыртынрак ат йөреше бар, алар аны ясады инде: Көнбатыш илләре 5 февральдән Россиядән нефть продуктлары сатып алуга эмбарго керттеләр. Хәзерге вазгыятьтә иң куркынычы менә шул эмбарго инде. Әйдәгез, «Российская газета»ны ачабыз да укыйбыз: «До 10% производимого в стране бензина и около половины дизельного топлива уходило на Запад. Также отправлялся за границу мазут – до 80%…» Безнең өчен монда 80% мазут дигәне әһәмиятле. Аны читкә сатмасаң да яшәп була, билгеле, бераз акча югалтасың. Тик эш акчага караганда катлаулырак. Мазутны куярга урын тапмагач, бездәге нефть эшкәртү заводлары туктарга мәҗбүр булачак. Белгечләр, нефть чыгаруны ике тапкыр киметергә туры килер, диләр. Бу да алай ук куркыныч түгел. Бәхәсләшмибез: зур югалту, тик түзәргә була. Нефть аз эшкәртелгәч, бензин аз булачак, бөтен хикмәт менә шунда. Илдә мотор ягулыгының зур дефициты пәйда булырга мөмкин. Сум түбәнгә тәгәрәр, бәяләр күтәрелер, бюджет кысыр калыр. Алардан да бигрәк бензин кытлыгы үзәккә үтәчәк. Совет чорын хәтерлисездер бит инде. Бензин салу кыен иде. Ул вакытта җиңел машиналар бармак белән генә санарлык иде. Шуңа авырлыгы бик сизелмәде. Хәзер күпкә кыен булачак.

Бу проблемага каршы Мәскәүдә берәр чара бардырмы? Бензинны читтән сатып алу планлаштырыламы (мәсәлән, Белоруссиядән), безгә караңгы. Бәлки, европалылар, эмбаргоны әйләнеп үтеп, безнең мазутны алу юлын үзләре табар? Алай да булгалый, тик өмет аз. Сабыр гына чишелешне көтәбез.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТОРМЫШ БӘЯСЕ

vk.com

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Узган елның 1 декабреннән ил күләмендә коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр күтәрелде. «Очрашу өчен бик күңелле сәбәп түгел. Тарифларны арттыруның чираттагысы киләсе елның 1 июлендә генә күтелсә дә, ә бәяләр гадәттә елга бер тапкыр үсә, ил Хөкүмәте карары нигезендә әлеге чара 2022 елның 1 декабренә күчерелде. Шул рәвешле, бер ел эчендә икенче тапкыр коммуналь хезмәтләргә бәяләр артты», – диде узган ел ахырында тарифлар үсүгә багышланган чарада Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев.

Гыйнвар башында әнә шул яңача исәпләнгән коммуналь түләү кәгазьләре килде дә инде. Без хәзер ут, газ, җылылык, су, пычрак суларны агызу һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгару өчен кыйммәтрәк түлибез. 1 декабрьдән республика күләмендә бәяләр уртача 9 процентка артты. Бер ел эчендә коммуналь хезмәтләргә бәяне ике тапкыр арттыруның сәбәбе дә билгеле: республикадагы инженер челтәрләренең өчтән бере тузган. Татарстанда 5900 чакрым озынлыкта су үткәргү, 1 мең чакрымнан артык озынлыкта җылылык челтәрен алмаштырырга кирәк. Кыскасы, ут янсын, су аксын өчен күбрәк түләргә туры киләчәк. Александр Груничев тынычландырырга да ашыкты: моннан ары коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәендә генә артачак. Тик саннар – бер, чынбарлык икенчерәк булып чыкты. Гыйнвар түләвен кулга алучылар чак кына артына утырмады.

Президент та белә

Иң кызу бәхәс интернетта купты. Чаллы халкы, ут-суга бәяләр чамадан тыш артык кыйммәтләнүгә ачыклык кертүләрен сорап, петициягә имза да җыя башлады хәтта. Әлеге хатны сигез меңгә якын кеше имзалаган инде. Социаль челтәрләрдә дә шау-шу дәвам итә. «Ноябрьдә 53 квадрат метрлы ике бүлмәле фатир өчен 4685 сум акча түләгән идем. Декабрь өчен 6 мең сумнан артык акча исәпләгәннәр. Вәгъдә ителгән 9 процент кыйммәтләнү кайда соң?» – дип язган Зәйдән Алинә Гобәйдуллина. «Ноябрьдә 1 Гкалл җылылык өчен 1920 сум түли идек, декабрьдә исә әлеге төр түләү 2093 сумга җиткән. Ярар, шулай булсын, ди. Ә җылылык өчен түләү ник 1910 сумнан 3820 сумга кадәр җиткән соң?» – дип зарланган Яшел Үзәннән Марат Вафин.

Республикада яшәүчеләрнең аһ-зарын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та ишеткән. Бу дүшәмбедә Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә ул коммуналь хезмәтләр өчен яңа бәяләргә бәйле шикаятьләр буенча тикшерү үткәрергә һәм халыкка тарифлар артуның сәбәпләрен аңлатырга кушты.

> Республика халкы декабрь аена яңа тарифлар буенча квитанцияләр ала башлады. Татарстан Төзелеш министрлыгына, район администрациясе башлыкларына һәм тиешле оешма җитәкчеләренә исәпләүләрнең дөреслеген тәэмин итәргә кирәк. Барлык шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр буенча тикшерү оештырыгыз. Халыкка түләү сәбәпләрен аңлату, шулай ук республикада гамәлдә булган социаль ярдәм чаралары турында сөйләү мөһим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына субсидияләрне вакытында түләүне тәэмин итәргә дә кушты.

Акча санаганны ярата

«ВТ» хәбәрчесенә бу айда 72 квадрат метрлы фатир өчен 9354 сумлык түләү кәгазе килде. Чагыштыру өчен, ноябрьдә түләү күләме 7214 сум тәшкил иткән. Декабрь өчен түләүнең шактый өлеше, тәгаен әйтсәк, 4222 сумы җылылыкка туры килә. Төп башына утыртканнармы әллә? Белгечләр исә, болай фикер йөртү дөрес түгел, ди.

– Ноябрь, декабрьдә һава торышы төрле. Шуңа күрә җылылык та төрлечә исәпләнә. Шул ук ут, кайнар суны тоту күләме дә айдан-айга аерыла. Шуңа күрә, узган айда азрак түләгәнмен, дип фикер йөртүчеләр ялгыша. Коммуналь түләү кәгазьләрен якынча чагыштырган очракта да, аны һич югы узган елның шушы ук чоры белән тәңгәлләштереп карарга кирәк, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин.

Аңлатма бирүләрен сорап, идарәче оешмага да шалтыраттык. Алар исә бу көннәрдә халыктан килеп ирешкән шикаятьләр күп булуына ишарәләп, язмача мөрәҗәгать итәргә киңәш иттеләр. «Кемгә күпме акча исәпләнүен ике сүз белән генә аңлатып булмый. Мәсәлән, җылылык күпме тотылганны белү өчен күпкатлы йортка кергән җирдә куелган исәпләгеч күрсәткечләрен алырга, аны мәйданына карап, фатирларга, гомуми кулланылыштагы урыннарга бүләргә, торак һәм торак булмаган бүлмәләрне аерырга кирәк. Барысын да аңлатып бирербез», – диделәр телефонның теге очында.

– Яңа бәяләр турында сөйләгәндә, былтыр тарифларның бер ел эчендә ике тапкыр артуын да истә тотарга кирәк, – ди Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары Светлана Заһидуллина. – Билгеле булганча, 1 июльдән республикада коммуналь хезмәтләргә бәяләр уртача 6,7 процентка кыйммәтләнде. Башкалада, мәсәлән, әлеге күрсәткеч 13 процентка җитте. Шуңа күрә узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, хәзер бәяләр 20 процентка кадәр кыйммәтрәк. Әнә шул үзен сиздерде дә инде.

«ВТ» хәбәрчесенең түләүләренә әйләнеп кайтсак, узган елның декабре өчен ул 8186 сум тәшкил иткән. Быелгысы белән чагыштырып карасаң, аерма 20 проценттан да кимрәк чыга. Исәпләүләр дөрес түгел дип уйларга җирлек юк, димәк.

2 миллион сум кайтарганнар

Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев әйтүенчә, түләү кәгазен кулга алгач та, иң элек кулланылган ут-су күләменә игътибар итәргә кирәк.

– Артык акча исәпләмәсеннәр дисәгез, ут-суга куелган исәпләгеч җайланмаларның күрсәткечләрен вакытында тапшырыгыз. Тарифларга бәйле сораулар туса, (843) 236-36-36 телефон номеры буенча Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының «кайнар линия»сенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты, аларның вакытында күрсәтелмәве яки исәпләүләргә бәйле шикаятьләр булган очракта, иң элек коммуналь хезмәтләр күрсәтүчегә, ягъни идарәче компания, торак хуҗалары ширкәтенә, ә алардан тиешле җавап булмаса яки ул канәгатьләндермәсә, Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә алаласыз, – ди Александр Груничев.

Халыктан килеп ирешкән барлык шикаятьләр ныклап тикшереләчәк, дип ышандырдылар Татарстан Дәүләт торак инспекциясендә.

– Без кулланучыларның хокуклары бозылырга мөмкин дип тапкан очракта тикшерү эше башлый алабыз. Хәзер исә безгә бер-ике җөмлә белән генә коммуналь хезмәтләр өчен бик күп исәпләгәннәр, дип язалар. Тик монда хокук бозу факты юк. Шунысын да әйтик: соңгы арада халык арасында бу мәсьәләгә бәйле ризасызлык зур булуын аңлап, без һәр очрак буенча идарәче оешмалардан аңлатма бирүләрен сорыйбыз. Тик бу гына тикшерү башларга сәбәп була алмый. Шуңа күрә тагын бер кат искәртәбез: коммуналь хезмәтләрдән риза булмаучылар, аңлатма бирүләрен сорап, иң элек әлеге төр хезмәтне күрсәтүче оешмага барырга тиеш. Идарәче оешма җавап бирмәсә яки ул җавап канәгатьләндермәсә, Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә аласыз. Безгә язган хатта идарәче оешмадан алган җавапны да беркетергә онытмагыз, – ди Светлана Заһидуллина.

11 гыйнварга алынган мәгълүматларга караганда, Татарстан Дәүләт торак инспекциясенә, коммуналь хезмәтләр өчен яңа бәяләрдән ризасызлык белдереп, 85 кеше мөрәҗәгать иткән инде. Узган ел милек хуҗаларына коммуналь түләү кәгазьләрендә арттырып күрсәтелгән 2 миллион сумнан артык акчаны кайтарганнар.

Районнарда ничек?

Чаллы Башкарма комитеты җитәкчесе Фәрит Сәләхов сүзләренә караганда, шәһәрдә җылылык өчен тариф – республика күләмендә иң түбән күрсәткечләрнең берсе.

– Әйтик, Зәйдә 1 Гкал җылылык энергиясе бәясе 2367 сум тәшкил итә, Түбән Камада ул – 2158 сум, Казанда исә 2136 сум тора. Автокалада әлеге тариф – 2093 сум. Татарстанның башка районнары белән чагыштырганда, Чаллыда тарифлар артык югары түгел. Җылылык челтәрләренең куллану вакыты – 20 ел. Димәк, бер елда аларның 5 процентын төзекләндерү зарур. Әгәр акча җитмәсә, әйтик, аларның 2 процентын гына төзекләндерәчәкбез. Ә калган 3 проценты шулай калачак һәм вакыты чыккан килеш эшләячәк. Бу исә аварияләргә китерергә мөмкин, – дип сөйләгән шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе журналистларга.

Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Роман Булатов әйтүенчә, тарифларны арттырмыйча да булмый. «Әлеге карар федераль дәрәҗәдә кабул ителде. Түбән Камада тарифларны арттыруны урынында карап тикшердек. Бәяләрне арттыруның сәбәпләре дә аңлашыла. Мәсәлән, «Водоканал» насосы электр ярдәмендә эшли, ә аны сатып алырга кирәк. Электр эшләп чыгаручы ТЭЦ исә газ сатып алырга мәҗбүр. Барысы да үзара бәйләнгән. Әгәр коммуналь хезмәтләр өчен акчаны дөрес исәпләмәгәннәр дип санайсыз икән, иң элек идарәче оешмага мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кулланучы буларак, үз хокукларыңны яклый белергә кирәк. Бу – дөрес юл, тик кайбер очракта бик җиңел түгел», – дип китергәннәр җитәкче сүзләрен районның рәсми сайтында. Башыңа төшсә, башмакчы булырсың, дип юкка гына әйтмиләр шул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ӨЧЕН ТҮЛӘҮДӘ СУБСИДИЯ КЕМНӘРГӘ ТИЕШ?

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә социаль ярдәм чараларының тулы бер комплексы гамәлдә. Федераль ташламага ия булучылар, ягъни Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр мондый хокуктан файдалана ала. Төбәк дәрәҗәсендә ташламага ия булучыларга хезмәт ветераннары, реабилитацияләнгән, репрессияләнгән гражданнар һәм күпбалалы гаиләләр керә. Андыйларга ташлама күләме, ярдәм чараларын алучыларның категориясенә карап, 30–50 процент тәшкил итә.

РФ Торак кодексының 159 нчы маддәсе нигезендә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә бәйле чыгымнар гаиләнең уртак керемнең билгеле бер чигеннән артып китсә, ә Татарстанда әлеге күрсәткеч 21 процент тәшкил итә, әлеге гаилә аз керемле булып санала һәм шулай ук субсидиягә өмет итә ала.

Субсидияне Дәүләт хезмәтләре порталы аша да рәсмиләштереп була. Бүген социаль ярдәм чаралары алучыларның 90 проценты документларны өйдән чыкмыйча гына тапшыра. Социаль яклау органына барган очракта, паспорт һәм исәп-хисап счеты кирәк. Калган мәгълүматны белгечләр үзләре туплаячак. Татарстанда субсидиянең уртача күләме 900 сумнан 1 мең 200 сумга кадәр тәшкил итә. Бүген Татарстанда 270 мең кеше – федераль ташламалардан, тагын 370 мең кеше төбәк дәрәҗәсендәге ташламалардан файдалана.

Сәрия МИФТАХОВА

ШӘҺӘРДӘН АВЫЛ КҮРЕНӘМЕ?



Илдар Мөхәммәтҗанов

Барысына бер дилбегә. Узган ел ахырында Россия Президенты Владимир Путин имзалаган закон район һәм шәһәрләрдәге мәгариф оешмаларын төбәкләр карамагына тапшыру мөмкинлеген бирә. Әлеге яңалык авыл мәктәпләрен ни дәрәҗәдә сөендерәчәк? Бер калыпка кертүнең нинди уңай һәм тискәре яклары бар?

«Ни ремонтка, ни җиһазга акчасы юк»

Закон проектын әзерләгәндә, әлеге яңалыкның укытучылар кытлыгын хәл итәргә, мәктәпләрдәге шартларны, белем сыйфатын яхшыртырга булышасын әйттеләр. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин белдергәнчә, бу мәсьәләләрне район һәм шәһәрләр үзләре генә хәл итә алмый. Ник дигәндә, аларның җиһазлар сатып алырга да, ремонт ясарга да, укытучыларны мәктәпкә җәлеп итәргә дә җитәрлек акчасы юк. Яңа закон исә авыл һәм шәһәр арасындагы шартларны тигезләргә, уку сыйфатын яхшыртырга, финанс чыгымнарын ачык итеп күрсәтергә ярдәм итәчәк, диләр. Һәрхәлдә, Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов та яңа законны бик җитди дип бәяләде. «Ул мәктәпләрнең генә түгел, анда белем бирүче укытучыларның да дәрәҗәсен күтәрәчәк. Төбәк идарәсе мәктәпләрне тиешле хезмәт хакы һәм кирәкле җиһазлар белән тәэмин итәргә булышачак», – ди федераль министр.

Бу уңайдан Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан да аңлатма сораган идек, тик анда табадан яңа гына төшкән канунга бәя бирергә ашыкмадылар.

– Без законнарны бәяли алмыйбыз. Министрлык – бары башкаручы гына. Мәгариф оешмаларын төбәкләргә тапшыру турында закон күптән түгел кабул ителде. Шуңа күрә нәрсәнең ничек үзгәрәчәген әлегә әйтә алмыйбыз, – диделәр.

Сан

Республикада **1411** гомуми белем бирү оешмасы бар. Анда **468933** укучы белем ала. **1993** бакчада **215882** бала тәрбияләнә.



Шәһәрдән күзәтеп булмый...

Элеккеге мәгариф министры **Васил Гайфуллин** исә фикерен әнә шулай белдерде. Идарәне күчерү белән килешми ул:

> Һәр район үз җирлегендәге бакча һәм мәктәпләргә күзәтчелек итмәгәч, башкаладагылар андагы хәлләрне ничек күреп бетерсен? 400 чакрым ераклыктагы авыл, вак шәһәр мәктәпләрен моннан гына күзәтеп булмый ул. Бу, киресенчә, контрольне киметүгә китерәчәк. Әле болай да шәһәрдәгесен күреп бетерә алмыйлар, – диде.

Аның фикеренчә, шартлар һәм хезмәт хакларын тигезләүне аерым закон чыгармыйча хәл итәргә мөмкин. Акчаны болай да бүлеп биреп була. Моның өчен Казанны Азнакайга яки Балтачка күчерергә кирәкми. Элеккеге министр финанс мәсьәләсен үзәкләштерү белән килешсә дә, башка маддәләре, киресенчә, буталчыклык китереп чыгарачак, дип саный.

Кайбыч районында бүген 16 мәктәп, 10 балалар бакчасы һәм мәктәпләрдә 8 мәктәпкәчә төркем эшли. Район мәгариф бүлеге башлыгы Илмас Хәмидуллин яңа законнан әллә ни уңай үзгәрешләр өмет итми.

– Мондый үзгәрешләр укытучы статусына тәэсир итәр дип уйламыйм. Укытучыга югары хезмәт хакы һәм дәүләт тарафыннан яклау җитә, минемчә. Республикада һәм безнең районда болай да мәктәпләрне караш начар түгел. Ә нигә тигезләргә? Авыл барыбер шәһәр була алмый. Һәрберсенең уңай һәм җитешмәгән яклары бар. Ләкин барысы да үз урынын таба. Авыл тәрбиясен шәһәрдә алу кыен. Шәһәр кешесе авылга кайтмый. Федераль, төбәк, муниципаль вәкаләтләр бүленгән. Үз өлешләрен тиешенчә үтәсәләр, без канәгать булыр идек, – ди Илмас Хәмидуллин.

Бер калыпка салмакчылар...

Балтач районының Бөрбаш мәктәбендә бүген 158 бала укый. Белем алу өчен шартлар җитәме? Бу хакта директоры **Мәлик Сибагатуллин**нан сораштык.

– Авыл мәктәпләре ярдәмгә һәрдаим мохтаҗ, – ди ул. – Элек әсбаплар белән тәэмин итү эше үзәкләштерелгән рәвештә алып барыла иде. Укыту базасы аерым статья нигезендә матди яктан баетылып торды. Хәзер андый мөмкинлек юк. Яңа җиһазлар бик аз кайта. Химия, физика кабинетларындагы кирәк-яраклар совет заманыннан калган. Реактивлар да кайтмый. Булган җиһазлар белән укытабыз. Чаңгылар җитә. Тупларны эшмәкәрләр аша табам. Үзебезнең мәктәпне тәмамлаган укучыларыбыз да онытмый. «Үсеш ноктасы» проекты бар. Әмма ул бөтен авыл мәктәпләренә дә бирелә дигән сүз түгел. Ярдәмне грантлар, бәйгеләргә калдыру да дөрес түгел. Аны бит гел отып булмый.

Кечкенәрәк булган саен, идарә итү җайлырак дип саный директор. Безнең проблеманы шәһәрдәгеләргә караганда район башкарма комитеты яхшырак белә, ди. «Һәр районның үзенчәлеге, финанс мөмкинлекләре, өстенлекләре бар. Бу барысын да тигезләүгә китермәсме? Өстән бер калып куеп, барысын шул кысага кертмәсме?» – дип шик белдерә Мәлик әфәнде.

Укытучылар исә хезмәт хакы артсын, хисап эшләреннән котылсак иде, дип өмет итә. Авыл укытучысы Зөлфия Исмәгыйлева да шундый хыяллар белән яши. «Яңа интерактив җиһазлар җитми. Гомумән, кабинетларга ремонт кирәк. Бәлки, хезмәт хаклары артыр, – дип өметләнә ул. – 18 сәгать укыткан укытучыларның хезмәте лаеклы хезмәт хакы белән бәяләнер. Хәзер алар 16 мең сум акча ала».

Мәктәпләр бетмәсен...

Хәзерге вакытта мәктәпләрне ябу мәсьәләсен районнар үзләре хәл итә. Әгәр идарә итү тәртибе төбәкләргә тапшырылса, бәлкем, кечкенә мәктәпләрне дә саклап булыр? Азнакай районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев белән шул һәм башка мәсьәләләр хакында сөйләштек.

– Республика карамагына күчүдән сыйфат үзгәрәме? Шул ук районнар, укытучылар, укучылар кала бит. Һәр җирлек үз мәгариф тармагының нечкәлекләрен яхшырак белә. Проблемаларны хәл итүне элеккеге тәртиптә калдырсак, яхшырак булмасмы икән? Соңгы елларда авыл мәктәпләренә игътибар артты. Авыл белән шәһәрдә аерма алай зур димәс идем. Финанс мәсьәләсенә килгәндә, субсидия, норматив буларак, нигә акчаны җирлекләргә күчермәскә? Миңа калса, шулай эшләгәндә нәтиҗә дә яхшырачак, – ди Дамир Гыйләҗев.

Җитәкчене мәктәпләрне кыскарту проблемасы да борчый. Оптимальләштерүнең авылларның киләчәгенә тискәре йогынты ясавын яхшы аңлый ул.

– Революциядән соң Азнакай районында 70ләп авыл, 20ләп хутор юкка чыккан. Халыкның күпләп шәһәргә агылуы авылларны бетерүгә китерде. Без районда мәктәпләрне саклап калырга тырышабыз. Мәктәбе беткән авылның киләчәге нинди булыр? Минемчә, мәгариф оешмаларын кыскартуны районнар элеккечә үзләре хәл итәргә тиеш, – ди Дамир Гыйләҗев.

Яшьләр ни ди?

Хәзерге әти-әни өчен балаларын түгәрәкләргә йөртү, аларның сәләтен үстерү мөһим. Авылда моның өчен мөмкинлекләр бармы? Балтач районында яшәүче элеккеге укытучы Азат Гафуровка (исеме үзгәртелде), авылында мәктәп кыскартылгач, шәһәргә төзелешкә барып эшләргә туры килә.

– Авылда мөмкинлекләр аз инде ул. Мәсәлән, бер танышым улын башка районга хоккей түгәрәгенә йөртә. Без дә кызыбызны район үзәгенә бию түгәрәгенә йөрттек. Ара якын түгел. Бик теләгәч, каршы килә алмадык. Хәзер район үзәгенә йорт салдык. Шартлар булмагач, яшьләрнең 8–10 проценты гына авылда кала. Авылны саклау өчен, мәктәпләрне кыскартмаска, эш урыннары булдырырга, түгәрәкләрне күбрәк ачарга кирәк. Шул вакытта яшьләр шәһәрдәге мөмкинлекләргә азрак кызыгыр иде, – ди Азат.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧИШМӘ СУЫ... БАЛ ТҮГЕЛ

Кеше организмының якынча 65 проценты судан тора, дип әйтәбез икән, димәк, эчә торган суыбызның да сыйфаты яхшы булырга тиеш. Тик бу чыннан да шулаймы? Без нинди су эчәбез? Эчә торган су сыйфатының кеше сәламәтлегенә тәэсире ни дәрәҗәдә зур? Белгечләр белән шушы сорауларга җавап эзләдек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Белгеч фикере

Рөстәм Мусин сүзләренчә, һәр районда да начар һәм яхшы сулы чишмәләрне очратырга мөмкин. Аларның сыйфатын анализ ясатмыйча гына да ачыкларга була. Торак пунктлардан читтәрәк урнашкан, ферма, чүплек, сәнәгать мәйданнары, эре оешмалар, гипс булмаган урыннарда бәреп чыккан чишмә суын 99 процент очракта чиста дип әйтергә була, дип саный ул. Әгәр аннан кешеләр озак еллар су ала, сәламәтлекләре начарланудан зарланмый, тәмгә тәмле, юшкыны утырмый икән, бу да суның яхшы сыйфатлы икәнлеген күрсәтә. Кеше аягы басмаган урындагы чишмәләрнең дә суы әйбәт булырга мөмкин. Шулай ук галимнәр үткәргән тикшерү нәтиҗәләре хәзерге вакытта кулланыла торган ашламаларның грунт суларына тискәре йогынтысы юклыгын күрсәткән.

Суга карап, саулыгыңны чамала

Гөлинә Гыймранованың әти-әнисе Апас районының Урта Балтай авылында яши. Ул авылларындагы суның сыйфатын ошатмавын әйтте.

– Башнядан килә торган су бер дә тәмле түгел. Үземнең әниләр суны чишмәдән алып кайтып эчәләр, шушы ук авылда яшәүче каенаналарда кайнап суынган суны бөтенләй авызга ала торган түгел. Элек аларга чишмә суы килә иде, суы тәмле иде. Ниндидер программа буенча авылда суны кабаттан керттеләр, шуннан соң аның сыйфаты бозылды. Без үзебез Казанда фатирга куелган фильтр суын эчәбез. Тәмсез дип әйтеп булмый, – диде ул.

Икенче бер газета укучыбыз Ләйсән Хәкимуллина Биектау районының Каенлык авылында тора.

– Күп еллар без кран суын файдаландык. Әмма эчәр, ризык әзерләр өчен суны башка авылдагы чишмәдән алып кайта идек. Чөнки якыннарым кран суының тәмсез булуын һәм бик нык юшкын утыруын яратмады. Анализлар да суның нормадан артык катылыгын күрсәтте. Өстәвенә сууткәргечнең суы да еш бетеп җәфалады. Шуңа күрә ике ел элек без ишегалдында скважина ясадык. Ике көнгә бер чишмәгә йөрергә туры килмәс дип өметләнгән идек, тик якыннарым барыбер чишмә суын үз итә. Мин су тәмнәрендә аерма сизмәсәм дә, башкалар чишмәнекен ярата. Шуңа күрә авылда яшәсәк тә, өйдә миннән кала кран суы эчкән кеше юк, – ди Ләйсән.

Нинди су эчәргә куркынычсыз булып санала соң? Әлеге сорауны КФУның Геология һәм нефть-газ технологияләре институтының геология һәм гидрогеология кафедрасы доценты, фәннәр кандидаты Рөстәм Мусинга бирдек.

– СанПиН нормалары буенча суда бер меңләп тирәсе органик һәм берничә дистә органик булмаган матдә булырга мөмкин, – диде ул. – Әлбәттә, органик булмаганнары күбрәк очрый. Ләкин аларның барысын да тикшерү гади кеше өчен мөмкин түгел. Мин иң гадиләренә генә тукталам. Без эчә торган суда билгеле бер күләмдә тозлар бар. Әгәр алар бер литр суда бер граммнан артмаса, су яхшы дигән сүз. Мондый төче су җирнең өске катламында 20–30 метрдан башлап 300 метрга кадәр тирәнлектә ята. Кайбер районнарда әлеге катлам бөтенләй 20–50 метр белән генә чикләнә. Тирәнрәк казыган саен, минераллашу (ягъни тоз күләме) арта гына. Нефть ятмалары тирәнлегендә (бу, мәсәлән, 1,5 километр) минераллашу бер литр суда 200 граммга кадәр җитәргә мөмкин. Коены тирәнрәк казыган саен, суы чистарак була, дип фикер йөртү дөрес түгел. Андый очраклар бик сирәк булырга мөмкин.

Галим әйтүенчә, игътибар итәргә кирәкле икенче элемент – суның катылыгы. Аны исә сөяк һәм йөрәк өчен кирәкле кальций һәм магний бирә. Яхшы суда ул бер литрга 4,5 мг тирәсе булырга тиеш. Кальций һәм магний булмаган суны даими рәвештә эчкән очракта, сөякләр, йөрәк белән проблемалар башланууы бар. Ә инде ул артып киткән очракта (каты су) эчке органнарга таш утыртырга сәләтле, шул ук вакытта мондый су яман шештән саклый.

Рөстәм Мусин шәһәр шартларында һәм башкалага якын булган районнарда яшәүчеләргә скважина, кое һәм чишмә суларын бары тик кайнатып кына эчәргә киңәш итә. Чөнки микроэлементларның нормадан артык булуы сәламәтлек өчен зыянлы гына түгел, куркыныч та, ди ул. Мәсәлән, судагы кайбер бактерияләр менингит, гепатит китереп чыгарырга сәләтле. Ә нитратның, организмда җыелып килеп, яман шеш авыруына сәбәп булуы бар. Синтетик-органик матдәләр, авыр металлар күп булган суны даими кулланган очракта, алар, организмда җыелып, шулай ук җитди авырулар китереп чыгарырга мөмкин. Әйтик, суда борның артык күп булуы нәсел калдыру сәләтен киметергә мөмкин. Сүз уңаеннан, башкалада су Дәрвишләр, Тау арьягы бистәләрендә аеруча начар икән. Галим казанлыларга краннан килгән суны фильтр аша чыгарып эчәргә киңәш итте. Ә менә зур шәһәрләрдән читтәрәк урнашкан, сәнәгать зоналары булмаган авыл халкы исә чишмә суларын тыныч күңел белән эчә ала, ди ул.

– 1990 елларда без, галимнәр, республикадагы кое, чишмә суларын күп тикшердек. Ул вакытта күпчелек коелардагы суның сыйфаты начар, кайнатмыйча эчәргә яраксыз булуын ачыкладык. Алардагы күп компонентлар тиешле нормадан артып китә иде. Кызганыч, чишмәләр белән дә шул ук хәл. Чишмә авылга никадәр якынрак, аның сыйфаты шуның кадәр начаррак. Шуңа күрә читтәрәк бәреп чыккан, озак еллар файдалануда булган чишмә суын эчәргә киңәш итәм, – диде Рөстәм Мусин.

Галим кайбер районнарга да тукталып узды. Әйтик, Татарстанның көньяк-көнбатышындагы районнарда (Чүпрәле, Буа районының кайбер өлеше) суның кызыл балчык белән кушылуы нәтиҗәсендә минераллашу бер литр суда 5–6 граммга кадәр җитәргә, катылыгы нормадан ун тапкыр артып китәргә мөмкин икән. Бу яклардагы суларда башка компонентларның да зур күләмдә очравын әйтте Рөстәм Мусин. Моннан тыш, Иделнең уң як яры – Югары Ослан районының Печище авылы тирәсендә туфракның өске катламында тиз эри торган гипс бар. Аның белән бәйләнешкә кергән су бик тиз тозлана һәм эчәргә яраксызга әйләнә. Мондый сулыклар Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында да (мәсәлән, Баулы, Мөслим) күп, ди галим. Көнбатыш Кама арьягы өчен, мәсәлән, авыл хуҗалыгы объектларының һәм табигый гидрогеологик шартларның (Чирмешән, Сөлчә һәм башка бассейннар) йогынтысы зур икән.

Кышын яхшырак

Татарстанлылар чишмә, кое, колонка (су баганасы) яки краннан аккан суларын тикшертү өчен, дәүләтнекенә һәм шәхси лабораторияләргә мөрәҗәгать итә ала. Соңгыларында бәяләр 1500 сумнан башлап 20000 сумга кадәр җитә. Лабораторияләр суларны микробиологик, санитар-химик (суның катылыгы, юшкын утыру-утырмавы, составында хлорид, сульфат һәм башка элементлар булу-булмавы) һәм органолептик күрсәткечләргә тикшерә.

Әйтик, Татар төбәкара ветеринария лабораториясенә су анализларын белер өчен гадәттә оешма җитәкчеләре, Казанга якын булган районнарда шәхси йортларда яшәүчеләр мөрәҗәгать итә. Узган ел, мәсәлән, бирегә 332 су пробасын кабул иткәннәр. Аларның 16сы таләпләргә җавап бирмәгән, микроблар һәм бактерияләр нормадан артып киткән.

– Гадәттә чишмә сулары чиста, ә скважинаныкы пычрак була. Аеруча яңа казылган коелардан алынган су микробиологик сыйфатлары буенча начар, ә үзәкләштерелгән сулар яхшы күрсәткечләр бирә. Алар гадәттә химик составлары белән генә аерыла. Әгәр чәйнек төбенә юшкын утыра икән, суны тикшертеп карарга киңәш итәбез. Анализ нәтиҗәләре буенча фильтр кулланырга мөмкин, – диде Татар төбәкара ветеринария лабораториясе директоры урынбасары Айдар Садриев.

Суны үзебез дә тикшертеп карарга булдык. Моның өчен Татар төбәкара ветеринария лабораториясенең әйдәп баручы белгече Гүзәлия Җамалетдинова белән бергәләп биш урыннан су пробасын алдык. Дөрес, әлегә аларның барысы да Казаннан алынды. Киләчәктә без район үзәкләре һәм авыллардагы суларны да тикшерергә уйлыйбыз. Шулай итеп, пробаларны 2 нче Азино урамындагы йорт почмагына куелган су автоматыннан, «Ключ здоровья» киоскыннан, Четаев урамындагы фатирның кран суыннан, 20 литрлы савытларда сатып алынган судан һәм йорт эчәнә куелган заманча фильтрдан чыккан судан алдык.

Анализ алыр өчен Гүзәлия иң элек спиртлы мамыкны яндырып, кранны дезинфекцияләде. Суны 5–10 минут агызып торганнан соң, стерильләштерелгән банкаларга тутырды. Җыелган суның күләме кимендә 3 литр булырга тиеш. Анализлар 7 көн эчендә әзер булды. Без тапшырган пробаларның барысы да химик һәм микробиологик анализ күрсәткечләре буенча нормадан артып китмәгән иде.

Дөрес, Айдар Садриев кышын су анализларының яхшырак булуын яшермәде. Чөнки бу вакытта җир туң була. Ә менә җәен кышын яхшы булган анализлар да начар күрсәткечләр бирергә мөмкин икән. Моннан тыш, иске йортлардан алып килгән суларның сыйфаты да күпчелек очракта начар булуын әйтте.

– Фильтрларга килгәндә, сәнәгать фильтрлары нәтиҗәлерәк, чөнки ул кыйммәтрәк булган саен, эшләве дә яхшырак. Ләкин аны куйганнан соң, бәйсез лабораториядә анализга биреп алырга киңәш итәм, – диде Айдар Садриев. – Кеше организмына су аша билгеле бер күләмдә микро һәм макроэлементлар керергә тиеш. Аларның бары тик тиешле нормадан артып кына китмәве кирәк. Әйтик, составында катылык бөтенләй булмаган суны да яхшы дип әйтеп булмый. Гадәттә, фильтр аша чыгарылган суда алар бик аз яки бөтенләй булмаска мөмкин. Анализлардан күренгәнчә, краннан аккан суның составында катылык бер литрга 4,5 мг булса, йорт янында урнаштырылган фильтрдан алынган суда ул нибары 0,45 миллиграммны гына тәшкил итә.

СЕЗ НИНДИ СУ ЭЧӘСЕЗ?



- Кран суы............38,4%
- Чишмә суы........33,33%
- Фильтрдан эчәбез..............21,07%
- Сатып алабыз.......7,2%

Газетаның ВК сәхифәсендә уздырган сораштыру нәтиҗәләре

СУНЫҢ БИК ПЫЧРАК БУЛУЫН КҮРСӘТҮЧЕ ТӨП БИЛГЕЛӘР

1. Судан ят ис килү.
2. Суны кайнаткач, чәйнек төбендә юшкын калу.
3. Суның болганчык булуы яки тора-тора тоныклануы.
4. Эчкәч, авызда тәмсез тәм калу.
5. Әлеге территориядә яшәүчеләрнең күпчелегенә хас булган авырулар да суның начар булуына ишарәләргә мөмкин.

16 гыйнвар | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00, 01.35 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ЮГАЛГАН ХАТИРӘЛӘР» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 Документальный фильм 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Адмирал». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 12+
00.45 «Каравай». Тайный смысл народных сказок 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 00.15 «Татар халык җырлары» 6+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.05, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. Основано на реальных событиях. Многосерийный фильм «Нулевой пациент» (S) 16+
22.35 «Большая игра» 16+
00.00 Светлана Ходченкова, Александра Ребенок, Анна Банщикова, Сергей Бурунов в фильме Валерии Гай Германики «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00, 03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Профилактика на канале с 6.00 до 10.00
10.00, 15.25, 21.55 Новости
10.05 Специальный репортаж 12+
10.25 Биатлон. Pari Чемпионат России. Суперспринт. Мужчины. Прямая трансляция из Рыбинска
11.20, 12.40, 14.05, 19.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
11.50 Биатлон. Pari Чемпионат России. Суперспринт. Женщины. Прямая трансляция из Рыбинска
13.10 Биатлон. Pari Чемпионат России. Суперспринт. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Рыбинска
14.20 Биатлон. Pari Чемпионат России. Суперспринт. Женщины. Финал. Прямая трансляция из Рыбинска
15.30 «Громко». Прямой эфир
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Металлург» (Магнитогорск). Прямая трансляция
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.00 Бильярд. «BetBoom Лига Чемпионов». Финал. Прямая трансляция из Москвы
00.50 Автоспорт. «Yuka Fest Ледовая миля». Трансляция из Вельска 0+
02.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. ЦСКА (Россия) – «Машека» (Белоруссия) 0+
03.30 Новости 0+
03.35 Биатлон. Pari Чемпионат России. Суперспринт. Мужчины. Финал. Трансляция из Рыбинска 0+
04.20 Биатлон. Pari Чемпионат России. Суперспринт. Женщины. Финал. Трансляция из Рыбинска 0+
05.00 «Громко» 12+

НТВ

05.25 Игорь Лифанов. «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ» (S) 12+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Денис Нурулин, Алексей Гришин, Евгений Куршинский. «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.00, 00.00 Дмитрий Ульянов. «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
00.25 Александр Устюгов, Сергей Жарков, Екатерина Климова, Юрий Беляев. «ЧУМА» (S) 16+
02.40 Дмитрий Миллер, Максим Щеголев, Сергей Никоненко, Егор Баринов. «БОМБИЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
07.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Пустая память» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.35 «Верну любимого» 16+
15.05 «ЕЁ СЕКРЕТ» 16+
19.00 «ПЕРВОКУРСНИЦА» 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Тест на отцовство» 16+
03.10 «Давай разведёмся!» 16+
04.00 «6 кадров» 16+
04.10 «НАПАРНИЦЫ» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

03.45 «МАРШ БРОСОК. ОСОБЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15 «ВЕСЕЛЫЕ РЕБЯТА» 6+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
14.00, 15.05, 03.50 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». «ОСТРОВ СМЕРТИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
16.05 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». «ПОПУТНЫЙ ВЕТЕР» 16+
18.55 «Восточный фронт». Док. сериал. «Маньчжурская операция» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Побег «Мулата». Разведчик Литвин» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ЛИХА БЕДА НАЧАЛО» 12+
00.55 «Бастионы России». Док. сериал 12+
03.10 «Зафронтовые разведчики». Док. сериал 16+

17 гыйнвар | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЮГАЛГАН ХАТИРӘЛӘР» 12+
13.00 «Татар халык җырлары» 0+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Гала-матч хоккейного турнира «Kazan-Cup». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Живи 1000 лет. Риза Фахретдинов. Часть 1 12+
00.40 «Каравай». Марийские музыкальные инструменты 6+
01.05 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Татар халык җырлары» 6+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» Телефильм 12+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.30 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
01.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00, 03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Валерий Харламов. На высокой скорости». Док. фильм 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 21.55 Новости
07.05, 14.25, 18.15, 22.00, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 01.45 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. UFC. Келвин Гастелум против Насрудина Имавова. Трансляция из США 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Что по спорту? Махачкала» 12+
13.50, 03.35 «Ты в бане!» 12+
15.55 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. «Толпар» (Уфа) – «Тюменский Легион» (Тюмень). Прямая трансляция
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/8 финала. Прямая трансляция
02.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Чеховские медведи» (Московская область) – «Пермские медведи» (Пермь) 0+
03.30 Новости 0+
04.05 «Голевая неделя» 0+
04.35 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
05.00 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри» 12+

НТВ

05.20 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ» (S) 12+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Исторический детектив «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.00, 00.00 Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
00.20 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
02.35 Сериал «БОМБИЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.50 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Рай в шалаше» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.40 «СЛАБОЕ ЗВЕНО» 16+
19.00 «УРОКИ СЧАСТЬЯ» 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.05 «Верну любимого» 16+
00.35 «Понять. Простить» 16+
01.35 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
04.05 «6 кадров» 16+
04.40 «НАПАРНИЦЫ» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». «ПОПУТНЫЙ ВЕТЕР» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 00.55 «ЛЮБОВЬ ЗЕМНАЯ» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
14.00, 15.05, 03.45 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». «КУЛОН АТЛАНТОВ» 16+
15.00 Военные новости 16+
16.05 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». «ВОСТОК – ДЕЛО ТОНКОЕ» 16+
18.55 «Восточный фронт». Док. сериал. «Боевые действия на Корейском полуострове» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ЖДИТЕ СВЯЗНОГО» 12+
02.30 «ЛИХА БЕДА НАЧАЛО» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының төбәкара һәм халыкара элемтәләрен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты директоры **Хәбибуллин** Эдуард Илтөзәр улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Прокурорының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча өлкән ярдәмчесе **Галиев** Руслан Марсель улы, Татарстан Республикасы Прокурорының мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү һәм гражданнарны кабул итү буенча өлкән ярдәмчесе **Литвин** Алексей Александрович, Татарстан Республикасы прокуратурасының федераль законнарның үтәлешенә күзәтчелек идарәсе норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек бүлеге (1 номерлы) өлкән прокуроры **Петрова** Ирина Степановна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы **Таишев** Марсель Мазһар улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Прокурорының махсус йөкләмәләр буенча ярдәмчесе **Насыйбуллин** Илнур Илдар улына, Татарстан Республикасы прокуратурасының тикшерү, башлап сорау алу һәм оператив-эзләү эшчәнлегенә күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары **Седов** Николай Андреевичка, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савиново районы прокуроры урынбасары **Селиваненко** Анастасия Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

СОҢ ЯТКАН ДАВЫЛГА БИРЕШӘ

Берәүләр бу чорны сызлану, баш авырту кебек борчу алып килгәне өчен яратмый. Икенчеләре андый көннәрдә җитди эшкә алынудан тыелып тора. Өченче берәүләр исә бу күренешнең нәрсә икәнен дә белми. Сүзебез – магнит давыллары турында. Магнит давыллары аяктан екмасын өчен ни эшләргә?

Табиб-невролог Диләрә ШАҺИЕВА белән шул хакта сөйләшәбез.

vk.com

Нәрсәдән гыйбарәт? Магнит давылы – җирнең магнит кырындагы тайпылышлардан гыйбарәт. Ул берничә сәгать эчендә генә дә күзәтелергә мөмкин. Кайчак магнит давыллары 3–5 көнгә дә сузыла. Әмма ничек кенә булмасын, бу чорның бер уңай ягы бар: ул организмга артык зур зыян салырга өлгерми.

Кемгә куркыныч яный? Магнит давыллары вакытында кан куера, тамырлар буйлап акрынрак хәрәкәт итә башлый. Шуңа күрә магнит давыллары вакытында иң беренче чиратта ишемия, гипертония кебек йөрәк-кан тамырлары авырулары булган кешеләр кәефсезләнә. Баш миенең кан тамырлары кысылган, инсульт кичергән кешеләр дә бу чорны авыр уздыра. Магнит давыллары вакытында өлкән яшьтәге кешеләргә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Ник дигәндә, яшь барган саен, кан тамырлары зәгыйфьләнә, тышкы көчләргә каршы тора алмый башлый. Нерв системасы какшаган кешеләргә дә бу чорда сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга киңәш ителә.

Нинди билгеләр буенча ачыкларга мөмкин? Магнит давыллары йогынтысына бирешүчән кеше иң беренче чиратта хәлсезлек тоя. Моннан тыш аны баш һәм йөрәк авырту да борчырга мөмкин.

Магнит давылларын сәламәтлеккә зыян салмаслык итеп ничек уздырырга?

- Әлеге чорны борчу-мәшәкатьсез генә уздырып җибәрү өчен, алдан хәстәрен күрергә кирәк. Әйткәнемчә, магнит давыллары вакытында кан куера. Шуңа күрә көненә 1,5–2 литр чиста су эчүне гадәткә кертегез.
- Туклануга да игътибар бирергә кирәк. Бу чорда куплап яшелчә, җиләк-җимеш ашау, балык ризыклары, төрле ярмаларга өстенлек бирү хәерле. Витаминнар эчү дә комачауламас.
- Ягу сезонында бина эчләрендә кислородка кытлык башлана. Бу, магнит давыллары башлангач, сәламәтлекне тагын да какшатачак. Шуңа күрә бүлмәләрне даими рәвештә җилләтү мәҗбүри.
- Эмоциональ яктан тотрыксыз кешеләргә үлән чәйләре эчү дә комачауламас. Мелисса, бөтнек, арыслан койрыгы (пустырник) үләннәреннән ясалган чәй аеруча яхшы тынычландыра.
- Магнит давылларын авыр кичерүчеләргә бу чорда физик күнегүләр ясау, спорт залына йөрүдән дә тыелып торырга киңәш итәр идем. Ник дигәндә, физик күнегүләр башкарганда кан агышы көчәя. Магнит давылы вакытында исә, әйткәнемчә, кан куерган була. Димәк, организмга икеләтә авырлык килә дигән сүз.
- Йокы режимын да җайга салырга кирәк. Соң йокларга яткан кеше төнлә бүленеп чыга торган гормоннарга кытлык кичерә. Организм көчсезләнә. Ахыр чиктә, кеше магнит давыллары йогынтысына да җиңел бирешә.

Гыйнварның икенче яртысында магнит давыллары

Гыйнвар	Көче/балл (5 баллы шкалада бәяләнә)
14	3
15	2
16	2
17	3
18	4
19	5
20	5
21	3
22	3
23	5
24	4
25	5
26	5
27	4
28	3
29	4
30	5
31	5

Халык медицинасы

Язга кыштан әзерләнәбез

- Язын организмга витаминнар җитмәгәндә, әфлисун согы ярдәмгә килә. Аны көненә бер стакан күләмендә эчәргә киңәш ителә.
- Витаминнарга кытлык чорында нарат ылысыннан ясалган төнәтмә дә файдалы. Аны әзерләү өчен бер стакан кайнар суга 40 грамм нарат ылысы салып, 20–40 минут төнәтергә кирәк. Соңрак аны сөзеп, көненә ике тапкыр ярты стакан күләмендә эчәсе.
- Сау-сәламәт булыйм дигән кешегә сарымсак белән дә дуслашырга туры киләчәк. Организм таләп иткән витаминнарны тиз арада үзләштерү өчен, көненә 3–4 тырнак сарымсак ашап кую да җитә. Сарымсактан төнәтмә ясап эчәргә дә була. Моның өчен 1 сарымсакның тырнакларын чистартып, 300 грамм спиртка салып, өч атна дәвамында төнәтергә кирәк. Шуны ярты стакан сөткә 20 тамчы салып, көнгә өч тапкыр эчәргә.

Сару кайнаса

Сару кайнауны бер тапкыр булса да татымаган кеше юктыр ул. Бу афәттән тиз генә ничек котылырга соң? Иң җиңел ысул – чәй урынына ромашка төнәтмәсе эчү. Иртәнге, көндезге һәм кичке аш алдыннан ярты чәй кашыгы бал кабып кую да файдага гына булачак. Активлаштырылган күмер дә сару кайнауны тиз арада басарга ярдәм итә. Ярты стакан суга бер чәй кашыгы сода салып эчү дә сару кайнаудан коткара. Ләкин сода белән сак булырга кирәк, еш кулланган, ул ашказанының лайлалы тышчасын зарарлый.

pinterest.com

ВИТАМИН КУЛ АСТЫНДА

Витамин	Ул җитмәгәндә, ниләр күзәтелә?	Нәрсә ашарга?
А	тән тиресе корый; биттә тимгелләр пәйда була	бавыр, йомырка сарысы, атланмай
В төркеме (B_1, B_2, B_5, B_6, B_9, B_{12})	тән тиресе кычыта; ирен читендәге яралар начар төзәлә; чәчләр корый, коела; ярсучанлык; кәеф төшү	эре итеп тарттырылган оннан пешерелгән ризыклар (B_1); сөт, ит ризыклары, кузаклылар (B_2, B_5, B_6, B_{12}); йомырка һәм диңгез ризыклары (B_3); бавыр (B_9)
С	еш салкын тия; хроник чирләр баш калкыта; яралар төзәлми; тән тиресе корый; хәлсезлек	яшелчә, җиләк-җимеш, җиләк, чикләвекләр
Д	башлангыч стадиядә аппетит югала, аяк буыннары сызлый, кул-аякларны көзән җыера; Д витаминына хроник кытлык башланган булса, тешләр бозыла, эндокрин системасында хилафлыклар пәйда була	бавыр, йомырка, балык
Е	тән тиресендә тимгелләр пәйда була; аяк чәнчи; тәннең кайбер өлешләре ойый; ярсучанлык, тиз ару	үсемлек майлары, йомырка, яшелчәләр
Р	кан тамырлары зәгыйфьләнә; тән тиресендә кара көйгән урыннар пәйда була; аяк һәм иңбашлар сызлый; хәлсезлек	цитруслар, алма, җиләк, помидор, чөгендер, кәбестә, кызыл борыч, карабодай

ТИР ИСЕ – ЧИР БИЛГЕСЕ

Гадәти булмаган тир исе берничә җитди авыру, шул исәптән яман шеш билгесе булырга мөмкин. Россия дерматологы Ирина Скорогудаева шулай дип белдергән. Табиб сүзләренә караганда, яман шеш авыруы башланган кеше кубрәк тирли һәм тирдән бозылган ит исе килә. Яман шешкә каршы көрәшкәндә, кешенең тән температурасы күтәрелә һәм аны төшерү өчен, организм терморегуляция системасын эшләтеп җибәрә. Шул рәвешле кеше нык тирли. Табиб белдерүенчә, шикәр авыруы булган кешеләрдән – еш кына ацетон яки пешкән алма, бавыр һәм бөер авырулары булганнардан аммиак исе килә.

Согы да шифалы



Икенче икмәк саналган бәрәңгенең согына кадәр файдалы. Ул иммунитетны ныгыта, холестерин күләмен киметә. Моннан тыш бәрәңге согы бавыр белән үт куыгын агулы матдәләрдән чистарта, ашказаны-эчәклек трактын эшчәнлеген дә яхшырта. Аның ярдәмендә икегә аерылган чәч очларын да дәвалыйлар. Моның өчен чәч төбенә бәрәңге согы сөртеп, 20 минут тоткач, юып төшерергә кирәк. Бәрәңге согы 10 минут эчендә бозыла. Шуңа күрә аны сыгу белән эчәргә кирәк. Ул 4–5 атна эчендә гастрит, колит авыруларын бетерә. 6–8 атна эчендә аның ярдәмендә ашказаны җәрәхәтеннән котылырга мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара
ЗИННӘТУЛЛИНА

ГАЕП СИНДӘ ТҮГЕЛ

«Гөл карый белмим, миндә барыбер үсмиләр!» Күп кенә хатын-кыз, бүләк ителгән яки сатып алынган гөлләре өйгә кайтуга үлгәннән соң, шулай ди. Өйне ямьләп торган гөлне ничек кенә хасиятләргә тырышсаң да яңарып китмәгәннән соң, әлбәттә, башка алырга да кул бармый, бүләк итсәләр дә, гөлне кызганып кына аласың. Шулай да үзегезне битәрләргә ашыкмагыз, монда гаеп сездә түгел, ә гөлнең язмышында икән.

vk.com

Хисләргә бирелмә

Бүләккә бирелгән гөлне, әлбәттә, кабул итми мөмкин түгел. Ә менә кайчак кибеттә матур гөл күрүгә, күзләр яна башлый, сатып аласы килә. Хисләргә бирелеп кенә гөл алырга ярамый. Сатып алганчы, аның турында бераз булса да мәгълүмат туплагыз: җылы, кояш яратамы, әллә күләгәне өстенрәк күрәме икәнлеген булса да белегез.

Алданма

Матур, сәламәт күренсен өчен, гөл сатучылар үстерә торган стимуляторлар яки туфрак урынына гидропоника (гөл туфраксыз үсә, файдалы матдәләрне махсус сыекчалардан ала) куллана. Әлбәттә, мондый гөл бөтен көчен үсүгә исраф итә, ә өйгә кайткач үсеп китәрлек хәле инде калмаган да була. Шулай итеп үсемлек өйгә кайтканнан соң берничә көннән үләргә дә мөмкин.

Яраннан башла

Кайберәүләр өендә джунгли ясарга ярата. Болай матурлыкка матур, тик бер үк төрле тәрбия ярамаган гөлләрне бер тәсле итеп тәрбияләгәндә, арада кайберләре, корып, кәефегезне кырырга мөмкин. Әгәр гөл тәрбияләргә артык вакытыгыз, талантыгыз юк икән, эшне тәрәзә төбендә берничә яран үстерүдән генә башлап карарга була. Чөнки яран нәзберек гөл түгел. Аннары бераздан алар янына башкаларын да өстәп, арттырырга мөмкин.

Тынычлык ярата

Кибетләрдән алган гөлләрнең тернәкләнеп китә алмавының тагын бер сәбәбе – аларның кояш яктысы җитмәгән, үсү өчен мөмкинлек булмаган киштәләрдә утырулары. Чәчәк ата башлаган вакытта тиешле шартларда тотмау аның үлеменә китерә. Транспортта алып кайтканда кирәгеннән артык селкетү, салкыннан җылыга, киресенчә, җылыдан салкынга алып чыгу да аның әле нык ыгып бетмәгән тамыр системасына тискәре йогынты ясый. Паразит бөҗәкләр зыян салмасын һәм гөлләр белән күчеп йөрмәсен өчен, аның төбенә күп итеп торф тутыралар. Ә ул бөтен гөлгә дә килешми. Дым һәм туклыклы матдәләр җитмәүдән интеккән гөл кибеттә үк яки аннан алып кайтып берничә көн үткәч шиңәргә мөмкин.

КИБЕТ ГӨЛЕН ТӘРБИЯЛӘҮ БУЕНЧА КИҢӘШЛӘР
- Бүләк ителгән гөлең берничә көннән сулса, үзеңне гаепләмә.
- Яңа гөлне башка гөлләрең янына түгел, башка җиргә куй. Аның белән корткыч бөҗәкләр иярөп кайтмаганмы? Яхшылап тикшер.
- Туфрагы гөлгә туры килмәвен чамаласаң, башка туфракка күчереп утырт.
- Күчергәндә тамырын яхшылап кара, кибет туфрагыннан арындыр һәм корыган тамыр очларын кисеп ал.
- Гөл тирәсендә вак чебеннәр барлыкка килсә, тамырын бераз марганцовка салган су белән эшкәрт.
- Артык дымнан зыян килмәсен дисәң, гөл чүлмәге төбенә вак керамзит ташлар сал.

Хуҗабикәгә

Өй эше

Бәйрәм ялларыннан соң өйне, бигрәк тә аш бүлмәсен рәткә китерер вакыт. Шуңа бергәләп эшләсәң күңеллерәк булыр дип, сезгә дә өй эше бирергә булдык.

ДҮШӘМБЕ
✓ Эшне плитәләрне юудан башлыйбыз. Тотынганчы, аның рәшәткәләрен җебетергә салып куябыз.
✓ Плитә янындагы «алъяпкыч» турында да онытмыйбыз, яхшылап чистартабыз.
✓ Аның янындагы өстәл өслеген дә ялт иттереп куябыз.

СИШӘМБЕ
✓ Кашык-чәнечкеләрне рәткә китерәбез. Сөртеп тутырабыз.
✓ Аш бүлмәсе гарнитурының аскы һәм өске фасадларын сөртәбез. Бигрәк тә аның тоткычларына игътибар итегез.

ЧӘРШӘМБЕ
✓ Мичне, аның рәшәткәләрен, табаларны юабыз.

ПӘНҖЕШӘМБЕ
✓ Вак көнкүреш техникасын – микродулкынлы мич, мультиварка, тостер, чәйнек, блендерларны чистартабыз.

ҖОМГА
✓ Бу көнне суыткычтагы кирәкмәгән әйберләрне ташлап, содалы су белән сөртеп алабыз.
✓ Ит һәм җиләкләр куелган өлешенә дә ревизия ясыйбыз.
✓ Өйдә булган продуктлар исемлеген язып, ике атналык меню төзибез.

Тәмле булсын!

ҮРДӘКЛЕ САЛАТ

Лилия ГЫЙНИЯТОВА рецепты

Какланган үрдәк ите – 100 г, микс-салат – 75 г, моцарелла сыры – 250 г, зәйтүн мае – 75 мл, алма серкәсе – 15 мл, төелгән кара борыч – 4 г, тәменчә тоз, кари – 2 г.

Каклаган үрдәк итен тире һәм сөякләреннән аралап, телемләп турарга. Моцарелланы да телемләп турарга һәм үрдәк ите, салат яфрагы белән чиратлап тәлинкәгә урнаштырырга. Соус өчен зәйтүн маена аш серкәсе, кари порошогы, тәменчә тоз һәм борыч салып, яхшылап болгатырга һәм табынга бирер алдыннан салат өстенә салырга.

ӘЧӘК БӨККӘНЕ

Резеда ФАЗЫЛОВА рецепты

Камырын җайлы гына итеп, ярты стакан үсемлек маена 1 стакан җылы су, тоз һәм сода, он салып бастым, ял иттердем. Эчлеге: шакмаклап туралган бәрәңге, иттарткыч аша үткәргән бозау әчәге, 4 баш суган, тоз һәм борыч. Пешеп чыккач, урталай ярып, эретелгән ак май сибеп ашадык.

Белеп тор!

Таймас өчен лайфхаклар

Аяк киеме таймасын дисәгез, түбәндәге киңәшләр сезнең өчен.

▶ Рулонлы лейкопластырьны кисеп, аркылыга ябыштырыгыз. Әлбәттә, ул озакка җитмәс җитүен, тик аны яңадан ябыштырып куюның бер кыенлыгы да юк.
▶ Чистартылган аяк киеме астына ПВА яки «Момент» келәе сөртеп, өстенә бераз эре бөртекле ком сибү шулай ук ярдәм итми калмас.
▶ Аяк киеменең үкчә һәм бармакларга якынрак өлешенә киез ябыштыру да ярдәм итәр. Шулай ук ПВА яки «Момент» келәе кулланырга мөмкин.

Исеңдә тот!

ЯНГА КАЛДЫРАБЫЗ

* Черри помидорын сатып алганда, савытларга тутырылганын түгел, ә килограммлап сатыла торганын алыгыз. Алай бәясе арзангарак чыга.

* Айсберг салаты гадәттә данәләп сатыла. Алар карап торышка бер төрле күренсәләр дә, авырлыклары төрлечә булырга мөмкин. Шунлыктан кассага барганчы үлчәп карагыз: аның 300 граммлысының да, 600 граммлысының да бәясе бер үк.

БӘЛА-КАЗА, ШАЙТАН КЕРМӘСЕН БАЛАГА

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) балалар хакында бер хәдисендә: «Балалар – тормыш чәчәкләре. Балалар – җәннәт күбәләкләре», – дип әйткән. Шик юк, сабыйларның дөньяга килүе – куанычлы вакыйга. Бала тугач, корбан чалу кебек матур гадәтебез дә бар. Аны «гакыйка» дибез. Аны ничек итеп дөрес чалырга? Ата-аналар өчен бу мәҗбүри гамәлме? Корбанлыкка дигән малга аерым таләпләр каралганмы?

Бу һәм башка сорауларга Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ белән ачыклык керттек.

:: Хәзрәт, «гакыйка» сүзенә ачыклык кертик әле. Ул нәрсәне аңлата?

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Гакыйка сүзенең мәгънәләре берничә. Иң төп мәгънәсе – яңа туган баланың башындагы чәче. Ислам динендә, сөннәт буенча, бала тугач та, 7 көн эчендә чәче алына. Баланың чәчен шушы корбанны чалганнан соң алганга күрә, әлеге корбан да «гакыйка корбаны» дип аталган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) гакыйка турында болай дип әйткән: «Бала сәламәт булсын дисәгез, кыз бала туган очракта – бер, ир бала туса, ике сарык чалыгыз». Күп кенә чыганакларда әйтелгәнчә, бала өчен гакыйка корбаны чалынса, ул күп кенә чирләрдән, бәла-казалардан, шайтан вәсвәсәсеннән имин була. Шуңа күрә, корбанны чалсак, бик яхшы. Бу гамәлне эшләсәң, савабы бар. Әмма эшләмәсәң дә гөнаһ түгел. Тик, әйтүемчә, чалынган очракта, сабыйның бәрәкәте була. Ускәч, аны бала үзенә атап, үзе дә чала ала. Әмма ата-ана башкарса, хәерлерәк. Бәби ашлары үткәрәбез бит инде, менә шул мәҗлескә дигән акчадан бер өлешен гакыйкага тотсак, әйбәт булыр.

Иң мөхиме – бу гакыйка корбаны Корбан гаетендә чалынырга тиеш түгел. Анысы – бүтән төрле корбан.

:: Гакыйка корбаны өчен мал нинди булырга тиеш? Аерым таләпләре бармы?

– Корбан гаетендәге сыман ук таләпләр. Мал сау-сәламәт булырга тиеш. Тәне дә төзек булсын. Әйтик, аягы, колагы, мөгезе сынган икән, андый малны корбан итеп чалу дөрес булмас.

:: Итне нишләтергә? Әйтик, аш уздырыргамы, мохтаҗ кешеләргә таратыргамы?

– Гакыйка корбанының ите өч өлешкә бүленә. Әйтик, туганнарны җыеп, мәҗлес үткәрергә мөмкин. Шулай да бер өлешен мохтаҗларга өләшсәк, хәерле була. Мәҗлесләр уздырырга мөмкинлек һәм вакыт юк икән, тулысынча мохтаҗ кешеләргә йә булмаса авыр хәлдәге кешеләрне кайгыртып торган махсус оешмаларга бирергә мөмкин.

:: Гакыйка корбанын чалуны ничә көндә башкарырга кирәк?

– Бала туганнан соң 7, 14, 21 нче көннәрдә чалына. Башка көннәрдә дә башкару мөмкинлеге бар, әлбәттә. Әмма нәкъ шушы көннәрдә чалынса, хәерлерәк. Мәҗбүри булмаса да, әйткәнемчә, гакыйка корбаны – бик мөһим гамәл ул.

«Татар-информ»

ГАКЫЙКА КОРБАНЫН ЧАЛУ ТӘРТИБЕ

- Корбанны чалганда, малны аяклары белән кыйблага каратып яткырырга.
- Чалучы кешенең мөселман булуы шарт.
- Мал чалган вакытта: *«Иннә саләәтии вә нусукии вә мәхйәәйә вә мәмәәтии лилләһи Раббил-гәәләмиин. Ләә шәриикә ләһ. Вә бизәәликә үмирту вә әнәә минәл-мүслимиин. Бисмилләһи, Әллааһү әкбәр. Әллааһүммә ләкә вә иләйкә (Аллаһның исеме белән чалам. Аллаһ иң бөек. Йа Аллаһ. Бу корбан Синеке һәм ул Сиңа кайта). Бу – фәлән улы фәләннең (баланың исеме әйтелә) гакыйка корбаны»*, – диеп әйтелә.

Гыйбрәт ал!

Аерылышканчы... күмәч пешер!

Хәзрәти Әбу Хәнифә янына бер хатын килә дә:

– Әй хәзрәт, ике ел элек ирем белән миңа никах укыган иде. Хәзер инде аер. Мин аның белән бергә яшәргә теләмим, – ди икән.

– Аерылышуның сәбәбе нидә? – дип сорый хәзрәт.

– Барлык хатыннарның ирләре өйләренә вакытында кайта, ә минеке һаман соңга кала. Шул сәбәпле кө көн дә диярлек өйдә тавыш чыга.

Әбу Хәнифә гаҗәпкә калып:

– Аерылырга теләвеңнең сәбәбе өйгә соңга калып кайтуда гынамы? – дип сорау бирә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Әйе, мондый кимчелеккә ия булган ир белән яшәргә теләмим. Башкалар кебек вакытында кайтсын, – дип җавап бирә хатын.

– Аеруын аерырмын, әмма бер шартым бар: өеңә кайт, зур, тәмле күмәч пешер һәм миңа алып кил. Аны пешергән вакытта бернәрсәне дә өеңнән алма: тозын да, суын да, онын да, йомыркасын да, сөтен дә күрше-тирә хатыннардан сорап ал. Сәбәбен дә аларга аңлат, – дип әйтә Әбу Хәнифә.

Бу хатын өенә кайтып китә. Күрше хатынына керә:

– Мәрьям, бер савыт су биреп тор әле, – ди. Күршесе исә:

– Суыгыз беттеме әллә? Сезнең ишегалдыгызда кое бар иде түгелме соң? – дип сорап куя.

– Суыбыз барын бар. Иремнән зарланып, хәзрәт янына: «Аер мине иремнән», – дип барган идем, – дип әйтүгә, күршесе Мәрьям:

– Әй, син минем иремне белсәң иде! – дип, озак кына иреннән зарлана башлый. Шуннан соң хатын башка күршесе янына тоз сорап керә.

– Тозың беттеме әллә? Бер кашык тоз сорап кергәнсең, – ди күршесе аңа.

– Тозыбыз бар барын, әмма иремнән зарланып, хәзрәт янына: «Аер мине иремнән», – дип барган идем, – дип әйтүгә, күрше хатын:

– Әй, син минем иремне белсәң иде! – дип, озак кына иреннән зарлана башлаган. Шулай итеп, бу хатын кайсы гына хатын янына нәрсә сорап керсә дә, барысының да ирләреннән зарлануын ишетә. Күмәчне бик зур, тәмле итеп пешерә. Хәзрәт янына алып барып, бу күмәчне аның кулына тоттыра.

– Әй хәзрәт, рәхмәт сиңа, күмәчне гаиләң белән тәмле итеп аша, әмма мине иремнән аера күрмә.

– Нәрсә булды, кызым? – дип сорый хәзрәт.

– Минем ирем барысының ирләреннән дә әйбәтрәк икән, – дип әйтеп куя хатын.

Сорау – җавап

Сорауларга җаваплар Рамил хәзрәт ЮНЫСОВның социаль челтәрдәге сәхифәсеннән тупланды.

? Мөселманнарга хаҗга бару мәҗбүриме?

– Хаҗ кылу мәҗбүри, әгәр дә ки өч шарты үтәлсә: барыр кулымда акча, исәнлек һәм юл имин булса.

? Әгәр дә ир: «Өйдән чыгып кит, әниеңә бар», – дисә, бу аерылуга саналамы?

– Ниятенә карап. Әйткән вакытта нияте чынлап та аерылу булса, талак санала, куркыту йә башка нният белән булса, талак түгел.

? Җәй аенда баланы сөннәткә утырту начар түгелме?

– Дин буенча гөнаһ юк. Медицина буенча әйтә алмыйм.

Йәгез, бер дога!

СӘДАКА АЛГАНДА УКЫЛА

«Әллааһүммә-хфәз саахибә хәәзиһис-садәкати ганил-әәфәәти вәл-бәләәйәә вәл-әмраад. Әллааһүммә-гъфирь зүнүүбәһү вә сәббит иимәәнәһү, вә сәккыйль мизәнәһү, вә бәәрик ләһү фии әмвәәлиһи вә вәффикһү галәә хайри мәкаасыйдиһи».

Мәгънәсе: «Йә Аллаһ! Бу сәдака иясен афәтләрдән, бәла-казалардан һәм авырулардан сакла. Йә Аллаһ! Аның гөнаһларын гафу ит, иманын ныгыт, мизан тәлинкәсендә әҗер-савапларны авыр кыл, байлыгына бәрәкәт индер һәм хәерле максатларына ирешергә ярдәм ит!»

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Бу юлы без рәсемнәр астына танылган совет фильмнарын яшердек. Беренче булып дөрес җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан фильмнарны беренчеләрдән булып Арчадан **Зөлфия Галәүтдинова** таныды. Бүләк – хуҗасында! Ә рәсемнәр астына «Иван Васильевич меняет профессию» (реж. – Леонид Гайдай), «Любовь и голуби» (реж. – Владимир Меньшов) һәм «Бриллиантовая рука» (реж. – Леонид Гайдай) фильмнарын яшергән идек.*

Җырчы әллә төшендә, әллә өнендә бер чибәр кызны күреп, аңа гашыйк була, «чынбарлык илләрендә бәхеткәе» булуын үтенә.

Әлеге җыр – туган якка мәхәббәт аңлату. Сөекле туган җирнең сихри тарту көче бар, ди җырчы.

Икәү булсак, хаталар булмас иде, давыл-бураннарга бирешмичә, язның назларын татыр идек, дип җырлана бу җырда.

ВИЛДАН ШӘМСЕТДИНОВ:

«НИ БУЛГАНЫН ҮЗЕБЕЗ ДӘ АҢЛАМЫЙЧА КАЛДЫК...»

Бүгенге сәхифәбезгә кунакка Вилли тәхәллүсе белән билгеле булган җырчы Вилдан ШӘМСЕТДИНОВны чакырдык. Башкортстанда туган егетнең балачагы ничек узган? Иҗатка мәхәббәт кемнән «сеңгән»? Тормыш иптәше Гөлназ Асаева белән кем «аерган» аларны? Без әнә шулар турында сөйләштек.

Вилданнан – Виллига

:: Ни хәл?
– Хәзер хәлләр ярыйсы, Аллага шөкер. Соңгы арада нинди вирус бар, барысын да үзем аша үткәреп бетердем, ахры...

:: Вилдан, балачагыгыз турында сөйләгез әле.
– Балачагым туган ягымда, әти-әни йортында – Башкортстанның Көергәзе районындагы Яңа Мораптал авылында үтте. Әтиемнең тугыз кыз һәм ир туганнары бар. Ун баланың алтысы төрле яклап иҗатка якын. Олатаем (әнинең әтисе) биюче, баянчы булган, мандолина һәм курайда уйнаган. Кыскасы, туганнарым арасында җыр-биюгә оста кешеләр дә, музыка уен коралларында уйнаучылар да бик күп. Кечкенә чакта мин дә, ничек тә алардан калышмаска тырышып, иҗатка тартылдым. Кечкенә сыйныфларда укыганда ук җырлар иҗат итеп, шуларны компьютерның микрофонына яздыра идем.

:: Тәүге тапкыр сәхнәгә чыккан көнегез исегездәме?
– Беренче тапкыр Башкортстанның Күмертау шәһәрендәге гимназия-интернат сәхнәсендә чыгыш ясадым. Ул көн әле дә хәтеремдә. Чыгыш алдыннан интернат бүлмәсендә бер егет белән сугыштык. Ул бүлмәдән күз төбем зәңгәрле-шәмәхәле булып чыктым. Шуңа күрә сәхнәгә кара күзлек киеп чыгарга туры килде...

:: Ни өчен зур сәхнәгә Вилли булып чыгарга уйладың?
– Оренбургта укыганда, ә бу 2013 еллар тирәсе, урыс егетләре, исемемне кыскартып, «Вилли» дип йөртәләр иде. Бераздан без алар белән җырлар яздыра башладык. Аларны чыгарганда, исемемне «Вилли» дип куя башладым. Ияләнеп киттем дә калды ул шулай.

:: Моннан ике еллап элек Элвин Грей һәм сезнең арада бәхәс чыккан иде. Гомумән, аның лейблына ничек килеп эләккән идегез сез? һәм ул бәхәс ничек хәл ителде?
– Лейблдан шалтыратып, тәкъдим ясадылар. Икенче тапкыр шалтыраткач, барырга булдым. Шулай эшләп киттек. Мин беркем белән дә бәхәсләшмәдем. Контрактны турыдан-туры лейбл белән түгел, башка кеше белән төзегән идем. Шуңа күрә тавышланып йөрмәдем.

Кем аерган?

:: Гөлназ белән ничек таныштыгыз?
– Нинди икәнен төгәл генә хәтерләмим, концерт вакытында танышып калдык. Ләкин ул концерттан соң берничә ел үткәч кенә аралаша башладык. Гөлназ белән безнең арадагы бәйләнеш ул – аерым тарих. Сөйләп, аңлатып бетерә торган түгел.

:: Кайсы сыйфатлары аеруча җәлеп итте?
– Гөлназны очраткач та, бу кыз миннән башка берәүгә дә эләгергә тиеш түгел, дип уйладым. Ул чакта аның сыйфатларын яхшыга һәм яманга аерып тормадым, ул мине шундук бар булмышы белән җәлеп итте һәм күңелдән китмәде. Шулай да, аның мөселманнарча тәрбияләнүе, сафлыгы аеруча ошады. Бергә булган еллар эчендә Гөлназның барлык сыйфатларына да гашыйк булдым. Барысын да аермыйча, бертигез хөрмәт итәм.

:: Булачак тормыш иптәшегезгә карата нинди таләпләр бар иде?
– Дөресен генә әйткәндә, нинди дә булса таләпләр турында уйланганым юк иде.

:: Вилдан, бер айлап элек матбугат чараларында һәм социаль челтәрләрдә, сезнең аралар өзелде, диган хәбәр йөрде. Имеш, Гөлназның менеджеры шулай дип әйткән. Сез ул чакта дәшми калдыгыз...
– Йокыдан уянып, кулыма телефонны алуга, ул яңалыкларга исем китте, аптырадым. Ни булганын үзебез дә аңламыйча калдык. Дус-туганнар да аптырады, аларны да тынычландырырга туры килде. Безнең бит пиар-менеджерыбыз да юк. Бары тик концерт директорыбыз гына бар. Ә ул концертлар өчен генә җавап бирә.

:: Димәк, имеш-мимешләр генә булды ул?
– Шулай булып чыга инде.

:: Сабыегыз – кызыгыз Динә үсеп килә. Әти булу ничегрәк соң?
– Динә якын дустыбыз кебек ул. Элек Гөлназ белән икәү генә җир җимертеп эшли идек, хәзер инде өчәү мәш киләбез. Динә бездән калмый диярлек. Кыз бала әтисе булуның иң мөһим өлеше ул – ярату һәм яратканыңны күрсәтү, минемчә. Ә бу миңа бик җиңел бирелә.

Блиц-сораштыру

– Буш вакытыгыз ничек уза?
– Студиядә эшлим, уеннар уйныйм.
– Мөмкинлек булса, тормышыгызны үзгәртер идегезме?
– Юк инде, ул кадәр әйберне үзгәртә башласаң... *(көлә)*
– Илһам чыганагы?
– Гаилә, тормыш үзе.
– Татар эстрадасында дусларыгыз күбрәкме, дошманнармы?
– Артистлар белән әллә ни аралашмыйм. Дошманнарым юк дип уйлыйм.

18 гыйнвар | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

Вниманию телезрителей! В связи с профилактическим ремонтом в среду, 18 января, телевизионные программы канала ТНВ с 02.00 до 09.00 не транслируются.
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00, 23.30 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «ЮГАЛГАН ХАТИРӘЛӘР» 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
14.15 «Туган авылым» 6+
14.30 Новости Татарстана 12+
14.45 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
18.30 Татарстан хәбәрләре 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Салават Юлаев». Прямая трансляция 6+
21.30 Новости Татарстана 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Спортивная среда» 6+
00.20 «Соотечественники». Живи 1000 лет. Риза Фахретдинов. Часть 2 12+
00.45 «Каравай». Национальные мотивы в живописи Бузунеевой 6+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 6+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

09.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
09.40 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» Телефильм 12+
13.05 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 12+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.05 «Әйдә, дустым, уйнат гармуныңны». Фән Вәлиахмәтов концерты 6+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «Нулевой пациент». Многосерийный фильм (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 «Краткий курс счастливой жизни» (S) 18+
01.00, 03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «Иван Зубков. Спаситель Ленинграда» 12+
02.55 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 21.55 Новости
07.05, 14.25, 22.00, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. One FC. Супербон Сингха Мавинн против Чингиза Аллазова. Трансляция из Таиланда 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 03.35 «Вид сверху» 12+
13.50 «География спорта. Крым» 12+
15.55 «Что по спорту? Махачкала» 12+
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Металлург» (Магнитогорск). Прямая трансляция
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Салават Юлаев» (Уфа). Прямая трансляция
21.25 «Ты в бане!» 12+
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/8 финала. Прямая трансляция
01.45 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит-Казань» – «Динамо» (Москва) 0+
03.30 Новости 0+
04.05 «Всё о главном» 12+
04.35 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+
05.00 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри» 12+

НТВ

05.25 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ» (S) 12+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Исторический детектив «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.00, 00.00 Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
00.25 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
02.35 Сериал «БОМБИЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.10 «Давай разведёмся!» 16+
10.10 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «Смертельное наследство» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.35 «Верну любимого» 16+
15.05 «ПЕРВОКУРСНИЦА» 16+
19.00 «ХРУСТАЛЬНАЯ МЕЧТА» 16+
23.20 «Порча» 16+
23.55 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.55 «Тест на отцовство» 16+
03.35 «Давай разведёмся!» 16+
04.25 «6 кадров» 16+
04.30 «НАПАРНИЦЫ» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ». «Восток – дело тонкое» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.00 «СУДЬБА». Фильм 1-й 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Токшоу 16+
13.20 «Москва фронту». Док. сериал 16+
13.50, 15.05, 03.35 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ЭКСПЕДИЦИЯ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.55 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ВОЗВРАЩЕНИЕ В ПРОШЛОЕ» 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Восточный фронт». Док. сериал. «Освобождение Сахалина и Курильских островов» 16+
19.40 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ЕСЛИ ВРАГ НЕ СДАЕТСЯ…» 12+
02.40 «Бастионы России». Док. сериал 12+

19 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЮГАЛГАН ХАТИРӘЛӘР» 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.30 Новости Татарстана 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – Казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00, 01.05 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Фаяз Хузин. Путешественник во времени 12+
00.40 «Каравай». Драматург нового времени И.Зайниев 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» Телефильм 12+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.05, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
00.15 «Халкым минем» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 «Краткий курс счастливой жизни» (S) 18+
01.00, 03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 09.45, 13.25, 14.20, 20.00 Новости
07.05, 14.25, 20.05, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.50, 13.30 Специальный репортаж 12+
10.10 «География спорта. Крым» 12+
10.40 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Белоруссии
12.00 «Есть тема!» Прямой эфир
13.50 «Лица страны». Лучшее 12+
15.55, 04.35 «Магия большого спорта» 12+
18.35 Смешанные единоборства. UFC. Тиаго Сантос против Яна Блаховича. Трансляция из Чехии 16+
20.55, 22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/8 финала. Прямая трансляция
01.45 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – «Пари НН» (Нижний Новгород) 0+
03.30 Новости 0+
03.35 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Спринт. Женщины. Трансляция из Белоруссии 0+

НТВ

05.25 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Исторический детектив «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.00, 00.00 Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
00.20 «Поздняков» 16+
00.35 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
02.45 «БОМБИЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Чудовище» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «УРОКИ СЧАСТЬЯ» 16+
19.00 «ИГРА В ДОЧКИ-МАТЕРИ» 16+
23.10 «Порча» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «Понять. Простить» 16+
01.45 «Тест на отцовство» 16+
03.25 «Давай разведёмся!» 16+
04.15 «НАПАРНИЦЫ» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ВОЗВРАЩЕНИЕ В ПРОШЛОЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.00 «СУДЬБА». Фильм 2-й 16+
10.50 «Освобождение». Док. сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Токшоу 16+
13.20 «Москва фронту». Док. сериал 16+
13.50, 15.05, 03.55 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ПЕРЕВОРОТ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.55 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ОБМЕН» 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Восточный фронт». Док. сериал. «Предотвращенная война» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ЗАБУДЬТЕ СЛОВО СМЕРТЬ» 12+
02.10 «ЖДИТЕ СВЯЗНОГО» 12+
03.25 «Вторая мировая война. Вспоминая блокадный Ленинград». Док. фильм 12+

20 гыйнвар | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести – Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 12+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Звёзды из Завтра-2022». Телефильм 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Татар халык җырлары» 0+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Авангард». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2023» 12+
23.10 «ПОСЛЕДНЯЯ РОЛЬ РИТЫ» 12+
01.05 «Каравай». История и традиции искусства войлока 6+
01.30 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – Казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Калеб» 6+
19.15 Концерт 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.55, 03.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Нәсыйхәт» 6+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 Р.Галиев. «КАДЕР КИЧӘСЕ». Т. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар дәүләт драма театры спектакле 12+
03.10 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос.Дети». 10-й юбилейный сезон (S) 0+
23.15 Кристина Асмус, Никита Ефремов. «ЗОЛУШКА» (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Данила Козловский, Владимир Машков, Катерина Шпица, Сергей Шакуров, Сергей Газаров, Елена Яковлева, Алёна Бабенко, Вячеслав Разбегаев, Василий Мищенко. «ЭКИПАЖ» 6+
00.15 Данила Козловский, Олег Меньшиков, Светлана Иванова, Владимир Меньшов, Роман Мадянов, Борис Щербаков. «ЛЕГЕНДА №17» 6+
02.35 Алексей Анищенко, Вероника Пляшкевич. «КРАСАВЕЦ И ЧУДОВИЩЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 09.45, 13.25, 14.20, 15.25, 19.00, 21.55 Новости
07.05, 14.25, 19.05, 22.00, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.50, 13.30, 01.10 Специальный репортаж 12+
10.10 «Что по спорту? Махачкала» 12+
10.40 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Белоруссии
12.15 «Есть тема!» Прямой эфир
13.50 «Лица страны». Лучшее 12+
15.30 Смешанные единоборства. One FC. Прямая трансляция из Таиланда
17.30 Матч! Парад 16+
18.00 «Ты в бане!» 12+
18.30 «География спорта. Крым» 12+
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Лейпциг» – «Бавария». Прямая трансляция
01.30 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Тюмень» – «Газпром-Югра» (Югорск) 0+
03.30 Новости 0+
03.35 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Спринт. Мужчины. Трансляция из Белоруссии 0+
05.00 «Магия большого спорта» 12+

НТВ

05.20 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.25, 10.35 «Следствие вели…» 16+
11.00 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Премьера. Исторический детектив «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.00 Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
23.55 «Своя правда» с Романом Бабаяном 16+
01.35 Сериал «БОМБИЛА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.50 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Зверь» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.40 «ХРУСТАЛЬНАЯ МЕЧТА» 16+
19.00 «КАРТА ПАМЯТИ» 16+
23.10 «Порча» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «Понять. Простить» 16+
01.45 «Тест на отцовство» 16+
03.25 «Давай разведёмся!» 16+
04.15 «По делам несовершеннолетних» 16+
05.05 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ОБМЕН» 16+
07.40, 09.20 «УЗНИК ЗАМКА ИФ». Фильмы 1-й и 2-й 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
13.20, 15.05 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ОХОТА НА МИЛЛИАРД» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.25, 18.40 «СЕКРЕТНЫЙ ФАРВАТЕР». 1-я – 4-я серии 12+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.00 «ЛЬВИНАЯ ДОЛЯ» 16+
01.55 «ЕСЛИ ВРАГ НЕ СДАЕТСЯ…» 12+
03.15 «Еж против свастики» 12+
04.00 «Перелом. Хроника Победы» 16+
04.25 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»-2. «ОХОТА НА МИЛЛИАРД» 16+

21 гыйнвар | Шимбә

ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Иөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Васил Гарифуллин 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.30 «Казаннан – Казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 И. Зәйниев. «БӘБИ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
15.15 «Тыңла әле мине...» Марат Мухин хитлары 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый мир»12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу» 12+
23.00 «КТО ЕСТЬ КТО?» 16+
00.50 «Вехи истории» 12+
01.15 «Спортивная среда» 6+
01.40 «Тыңла әле мине...» Марат Мухин хитлары 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Иөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Иөрәктән – йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 И.Зәйниев. «БӘБИ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – Казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Гомер чишмәм». Татарстанның халык артисты Рәсим Низамов концерты 6+
23.00 Ф. Хөсни. «ЙӨЗЕК КАШЫ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 12+
01.05 «Иөрәктән – йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телеочерк 6+
03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ
06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «ПроУют» (S) 0+
11.10 Премьера. «Поехали!» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 К 80-летию прорыва блокады Ленинграда. Премьера. «Ладога. Нити жизни» 12+
13.15 Андрей Мерзликин, Ксения Раппопорт, Алексей Серебряков. «ЛАДОГА» (S) 16+
17.10 «Угадай мелодию». 20 лет спустя (S) 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Горячий лед». Кубок Первого канала по фигурному катанию 2023. Прямой эфир (S)
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 Юлия Пересильд, Константин Хабенский, Виктория Исакова. «ТРОЕ» (S) 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.40 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.45 Мария Куликова, Егор Бероев, Александра Власова, Нина Усатова, Александр Ратников, Александр Никитин, Валерий Сторожик, Сергей Колесников, Алёна Коломина. «ТЕОРЕМА ПИФАГОРА» 16+
18.00 «Привет, Андрей!». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Елена Аросьева, Дмитрий Миллер, Юрий Батурин, Анна Бачалова. «МЕСТО СИЛЫ» 12+
00.45 Евгения Осипова, Андрей Фролов. «ГОРОДСКАЯ РАПСОДИЯ» 12+
04.10 Елена Дудина, Александр Пашков, Тамара Сёмина. «Я ПОДАРЮ ТЕБЕ ЛЮБОВЬ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 15.25, 17.20, 22.00 Новости
07.05, 13.55, 16.45, 19.30, 22.05, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БОЛЕКА И ЛЁЛЕКА». Мультипликационный фильм 0+
10.40 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Белоруссии
11.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Тюмень» – «Газпром-Югра» (Югорск). Прямая трансляция
14.15 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Белоруссии
15.30 «Король ринга. Николай Королёв». Документальный фильм 12+
17.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Вольфсбург» – «Фрайбург». Прямая трансляция
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Салернитана» – «Наполи». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Торино». Прямая трансляция
01.30 Смешанные единоборства. One FC. Трансляция из Таиланда 16+
03.30 Новости 0+
03.35 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Гонка преследования. Женщины. Трансляция из Белоруссии 0+
04.20 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Гонка преследования. Мужчины. Трансляция из Белоруссии 0+
05.15 «На гребне северной волны». Документальный фильм 12+

НТВ
04.50 Андрей Чубченко в детективном сериале «СТАЖЁРЫ» (S) 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 Научное расследование Сергея Малозёмова 12+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион. «ДНК Анны Казючиц» 16+
23.25 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном 16+
00.05 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Григорий Лепс (S) 16+
01.40 Сериал «БОМБИЛА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «ИСКУПЛЕНИЕ» 16+
08.45 «ТРОЕ В ЛАБИРИНТЕ» 16+
11.05 «ЛЮБОВЬ ВЕРЫ». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 124-я – 127-я серии 16+
22.30 «ДОМ НА КРАЮ ЛЕСА» 16+
02.05 «ЛЮБОВЬ ВЕРЫ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.30 «СЕМЕЙНАЯ ТАЙНА» 16+

ЗВЕЗДА
06.10 «ЦАРЕВИЧ ПРОША» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.15 «Победоносцы» 16+
09.35 «ВОЛГА-ВОЛГА» 6+
11.45 «Легенды музыки» 12+
12.10 «Легенды кино». Анатолий Равикович 12+
13.15 «Время героев». Премьера! 16+
13.35 «Главный день». «Северный полюс-1 и Иван Папанин» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
15.10 «Не факт!» 12+
15.35 «Война миров». Док. сериал 16+
16.25, 18.30 «На острие прорыва. Саперы особого назначения». Док. сериал 16+
20.10 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». Док. сериал 16+
23.05 «НАЙТИ И ОБЕЗВРЕДИТЬ» 16+
00.35 «Герой 115». Док. фильм 16+
01.50 «ЗАБУДЬТЕ СЛОВО СМЕРТЬ» 12+
03.05 «Зафронтовые разведчики». Док. сериал 16+
03.45 «СЕКРЕТНЫЙ ФАРВАТЕР». 1-я и 2-я серии 12+

22 гыйнвар | Якшәмбе

ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.20 «Синең өчен». Зәйнәб Фәрхетдинова 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Әйлән дөнья». Ришат Фазлыйәхмәтов концерты 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Дания Нуруллина 12+
22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
23.00 «ӘБИГӘЙЛ» 6+
01.00 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Оныта алмыйм...» 0+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Адымнар» 12+
07.30 «Узып барышлый». Гөлнара Сабирова җырларыннан концерт 6+
09.30, 15.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Яшәү – мизгел». Татарстанның халык артисты Нәфкать Нигъмәтуллин концерты 6+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
22.00 «Риваять» этно төркеменең юбилей кичәсе 6+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
02.50 «Адымнар» 12+
03.20 «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь». Рҗаил Зәйдуллаңың юбилей кичәсе 12+

1 КАНАЛ
05.10 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА» 12+
06.00 Новости
06.10 «Гусарская баллада» 12+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.00 К 125-летию гения. Фильм Сергея Эйзенштейна «БРОНЕНОСЕЦ «ПОТЕМКИН» 12+
15.45 Александр Ширвиндт. «Две бесконечности» (S) 16+
17.00, 19.00 «Горячий лед». Кубок Первого канала по фигурному катанию 2023. Прямой эфир (S)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
21.00 «Время»
22.35 Премьера. «КОНТЕЙНЕР» (S) 16+
23.35 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
06.15 Ольга Сухарева, Анна Якунина, Евгений Ганелин, Александр Никитин. «ЖЕНА ПО СОВМЕСТИТЕЛЬСТВУ» 16+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.40 Премьера. «Большие перемены»
12.45 Мария Куликова, Егор Бероев, Александра Власова, Нина Усатова, Александр Ратников, Александр Никитин, Валерий Сторожик. «ТЕОРЕМА ПИФАГОРА» 16+
17.00 Вести
18.00 «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Сергей Векслер, Светлана Чуйкина, Игорь Миркурбанов, Дарья Мельникова. «ЖЕНИХ» 16+
03.10 «ЖЕНА ПО СОВМЕСТИТЕЛЬСТВУ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. UFC. Гловер Тейшейра против Джамала Хилла. Прямая трансляция из Бразилии
09.30, 10.35, 12.55, 15.35, 17.50, 22.00 Новости
09.35, 12.05, 15.05, 17.20, 22.05, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.40 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Белоруссии
13.00 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
13.50 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Белоруссии
15.40 Смешанные единоборства. UFC. Гловер Тейшейра против Джамала Хилла. Трансляция из Бразилии 16+
17.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Специя» – «Рома». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Аталанта». Прямая трансляция
01.30 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Локомотив» (Калининградская область) – «Динамо» (Москва) 0+
03.30 Новости 0+
03.35 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Масс-старт. Женщины. Трансляция из Белоруссии 0+
04.30 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Масс-старт. Мужчины. Трансляция из Белоруссии 0+
05.30 «Что по спорту? Махачкала» 12+

НТВ
04.50 «СТАЖЁРЫ» (S) 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Звезды сошлись» 16+
21.50 «Основано на реальных событиях». «Шура показывает зубы» 16+
01.15 «ЛОВУШКА» (S) 16+
02.35 Сериал «БОМБИЛА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «СЕМЕЙНАЯ ТАЙНА» 16+
09.00 «ДОЛГОЖДАННАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
10.55 «ИГРА В ДОЧКИ-МАТЕРИ» 16+
14.55 «КАРТА ПАМЯТИ» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 128-я – 131-я серии 16+
22.35 «ГДЕ ЖИВЁТ НАДЕЖДА?» 16+
02.05 «ЛЮБОВЬ ВЕРЫ» 16+
05.10 «ДОЛГОЖДАННАЯ ЛЮБОВЬ» 16+

ЗВЕЗДА
06.00 «СЕКРЕТНЫЙ ФАРВАТЕР». 3-я и 4-я серии 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №126» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии». Николай Колосов 12+
13.05 «Специальный репортаж» 16+
14.00 «МАРШ-БРОСОК. ОХОТА НА «ОХОТНИКА» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «ВТОРЖЕНИЕ» 12+
01.30 «НАЙТИ И ОБЕЗВРЕДИТЬ» 16+
02.55 «Зафронтовые разведчики» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц
radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 16 гыйнвар
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Шамил Бикчурин. «Кошлар да туган якларына кайта». Радиотамаша
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердашханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 17 гыйнвар
6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Әсхәт Хисмәт җырлый

Чәршәмбе, 18 гыйнвар
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Шакир Мәҗитов әсәрләре

Пәнҗешәмбе, 19 гыйнвар
6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Ренат Ибраһимов язмалары

Җомга, 20 гыйнвар
6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Нажар Нәҗми шигырьләренә җырлар

Шимбә, 21 гыйнвар
8.10 Баянчы һәм фольклорчы Оркыя Ибраһимованың туууына 110 ел тулуга багышланган программа
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10 Галимҗан Ибраһимов. «Казакъ кызы». Радиоспектакль. 4 серия

Якшәмбе, 22 гыйнвар
8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Дирижер, Казахстанның һәм Россиянең халык артисты Фуат Мансуровның туууына 95 ел тулу уңаеннан концерт
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Галимҗан Ибраһимов. «Казакъ кызы». Радиоспектакль. 5-6 серия

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Ярдәм кирәк кешегә сиделка хезмәте күрсәтәбез. «Помощник» социаль хезмәте.
БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН: 8 (929) 962-76-44

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

КҮРӘЗӘЧЕ САННАР

ТОРМЫШНЫ ҮЗГӘРТҮ ӨЧЕН САН ҺӘМ КАРТАГА ГЫНА КАРАУ ҖИТӘМЕ?

«Карма», «код», «чакра», «ресурс», «цикл», «энергия»... Бу сүзләр колак өчен ят булса да, бүгенгебезне, бик күпләрнең көндәлек тормышын тәшкил итә, кайсыларның икмәге булып та тора. Үзеңне өйрәнү, үзең һәм бу дөньядагы ролең турында белергә теләү, рухи гармониягә омтылыш – барысын да саннарга мөрәҗәгать итеп төшенергә мөмкин. Шулар белән шөгыльләнүче нумеролог һәм тарологлар торган саен популярлаша.

pexels.com

Саннар теле

Резеда Әлмиева – нумеролог. Алдан ук укучыларыбызны кисәтеп куябыз: язмада ят терминология күп булачак.

– «Тормыш матрицасы», аны әле «җан матрицасы» дип тә атыйлар, реинкарнация теориясенә буйсына. Ягъни кеше Җир шарында берничә тормыш яши, һәр тормышта ул нәрсәгәдер өйрәнә (беренчесендә, мәсәлән, эшләргә һәм хезмәт куярга, икенчесендә яратырга, кешеләргә карата ягымлы булырга). Һәр тормышның – үз дәресләре, нәтиҗәләре, алар энергия белән күрсәтелгән. Энергия саннар белән бирелгән, алар 22гә кадәр. Шәхес типлары Тародагы «өлкән аркан»нар аша анализлана. Бу ысул, шулай итеп, таро-нумерология һәм карма мәгълүматларына таянган, – дип сөйләде Резеда. – Матрицаны ясау өчен туган көнен белү кирәк, кайбер вакытта кешенең ике датасын – чын һәм паспорттагысын да анализларга туры килә, чөнки икесе дә мөһим. Берсендә кешенең – эчке, икенчесендә тышкы характеристикалары яхшырак ачыклана.

Резеда сөйләвенчә, саннар аша бер белмәгән кешеләрнең дә тормышка карашларын, эшчәнлеген, җәмгыятьтәге урынын, теләк-омтылышларын ачыкларга мөмкин. «Танышларның матрицасын карагач та, нишләп ул менә шулай эшли икән дигән сорауга җавап табам», – дип сөйли тылсымлы өлкәсе турында Резеда.

Аңа мөрәҗәгать итүчеләр күбесенчә үзләренең бу тормыштагы урынын (предназначение) аңлау өчен килә икән. «Гадәттә, кешеләр бизнес ачканда яки үз һөнәрендә ниндидер кризис булганда мөрәҗәгать итә. Финанс, мәхәббәт өлкәсендә гел кабатлана торган хәлләр булганда да еш киләләр. Узган елның июленнән консультацияләр бирә башладым. Аена 8–10 кеше була. Рухи азыкка омтылыш инде берничә ел актив күзәтелә һәм тора-бара тагын да активлашыр, дип уйлыйм», – дип фаразлый әңгәмәдәшебез.

Эзотерик практикларга мөрәҗәгать итүчеләр, аларның ярдәмен көтүчеләр ник күп соң, нишләп алар психологка бармый?

– Бердән, безнең халык бик борчулы. Алар гел нәрсәдер турында уйлый. «Горе от ума» диярсең, билләһи. Кешегә һәрвакыт нәрсәнедер чәйнәп бирүче, аңлатучы кирәк. Хәзер дөньяны «ак» һәм «кара»га бүлеп булмый, ә кешегә тыныч булып калу һава кебек кирәк. Борчулыга өстәп, бездә үз-үзеңә ышаныч юк һәм үзбәя бик түбән. Кайбер кешеләр консультацияләргә үз-үзенә игътибар кирәк булганга да килә. Кешеләрне мактаучы, алар белән сокланучы, аларга «син барысын да дөрес эшлисең» дип әйтүче чыганак кирәк. Гомумән, таро, наталь карталар һәм матрица – болар барысы да инструмент кына, дөрес кулланса, алар тормышта күп әйберне аңлатырга сәләтле, – ди Резеда.

Бу мәйданчыкта кырыгалдарлар да шактый, әлбәттә. Алданмас өчен нишләргә?

– Белгеч турында күбрәк мәгълүмат табарга, аның эшенә карата бәяләмәләрне күзәтеп чыгарга кирәк, – дип киңәш итә Резеда Әлмиева. – Белгечне сайлаганда, эчке хис-кичерешләрне дә тыңларга онытмаска. «Тылсымлы дару» эзләп түгел, аңа конкрет сорау белән барырга. Мисал өчен, гаиләдәге эчкечелек проблемасын ничек хәл итәргә? Белгечкә баргач, үзең белән эшләргә әзер булырга кирәк. Киңәшләргә күз йоммаска. Мошенник корбаны булган очракта, сөйләшүләрне, хат-хәбәрләрне, банк аша акча күчерү турында мәгълүматны сакларга.

Картадан ни көтәргә?

Казанның Мәскәү урамында кабул итүче таролог исемен күрсәтмичә генә сөйләшергә булды. «Багучы, күрәзәче дип әйтмәсеннәр өчен», – ди. Бездәге халыкта скептицизм әле көчле, диюе инде. Югыйсә Таро карталарында багу бик борынгы тәҗрибә санала һәм бөтен дөньяда кулланыла. Таролог, мәгълүм булганча, махсус карталар белән эшли, фал ача.

– Шәхси тормыш, мөнәсәбәтләргә бәйле юнәлештә эшлим. Хәзер күбрәк шундый сораулар белән киләләр дә. Әйтик, яныгызда сезгә тиң кешеме, якын киләчәктә ялгызлар кемне очратыр, бер-береңне аңлау өчен нишләргә, мөнәсәбәтләрнең киләчәге нинди? Шулай ук акча, эш, карьера, бизнес буенча мөрәҗәгатьләр белән дә эш итәм. Мин киңәшләрне тәҗрибәле психолог буларак та бирәм. Кешенең энергиясен аңлау өчен, аның исеме, туган елы, фотосурәте һәм кыскача гына нинди проблема-сорау белән килүен белү мөһим. Беркайчан да үземнән уйлап чыгарып сөйләмим. Мин эш иткәндә Якты көчләргә генә таянам. Фаразларым төрле була. Әмма карта һәрвакыт теге яисә бу мәсьәләне төзәтеп, дөрес якка борып җибәрергә киңәш бирә, – ди ул. – Әлбәттә, ил-көн яңалыкларына бәйле рәвештә киләчәк турында сораучылар да бар. Фаразлар, вазгыятьнең нинди якка борылуы турында ишетергә телиләр.

Ул онлайн да кабул итә. Кешеләр белән социаль челтәрләр аша да борчыган сорауларына ачыклык кертеп була икән. Бер сорауга җавап яисә бер юнәлешкә бәйле картада онлайн багу 300 сум тирәсе булса, очрашып сөйләшү 1 мең сумнан башлана.

Ышанырга түгел ышанмаска

Өтерне кайсы урынга куясын һәркем үзе хәл итә, әлбәттә. Безнең максат – хурлау йә мактау түгел, аңлату гына. Әйтик, ни өчен эзотерик күренешләр хәзер аеруча популяр? Нигә аңа ышану дәрәҗәсе шулай зур?

Баксаң, кичә-бүген барлыкка килгән үзгәреш түгел икән инде бу. Коронавирус пандемиясе чорыннан ук башланган ул. Әйтик, 2021 елда ук китап нәшер итү белән шөгыльләнүче зур компанияләр халыкның эзотерика буенча китаплар белән кызыксынуының кискен артуына игътибар иткән иде. Мәсәлән, «Эксмо» нәшрияты мәгълүматлары буенча, аларның мондый төр китаплары 53 процентка күбрәк сатылып, 400 млн сум табыш китергән. Чагыштыру өчен: 2020 елда әле бу сан 13 процент тирәсе генә булган.

Китаплар белән бергә, багу карталарына да ихтыяҗ арткан. Әйтик, соңгы елда Wildberries маркетплейсында Таро картасын 486 процентка күбрәк алганнар.

Психологлар исә кешеләрнең эзотерикага һәм эзотерика белән мавыгучыларга мөрәҗәгать итүенең берничә сәбәбен атый.

Клиник психолог Павел Жавнеров аңлатканча, кешеләр теге яисә бу мәсьәләнең гади чишелешләрен эзли. Психолог сүзләренчә, эзотерикага күбесенчә эмоциональ яктан тотрыксызрак кешеләр бирелә. Бу күренешләргә ихтыяҗ артуга исә соңгы арада булган вакыйгалар тәэсир итә. Әйтик, дөньякүләм проблемалар, бәяләр үсеше. «Болар барысы да кешегә йогынты ясый, ул үзен бу хәлләрдән сакларга, рухи яктан тынычландырырга тели. Эзотерика җиңел җаваплар бирә», – дигән фикердә белгеч.

Фән кырында исә фаразлаучы һәм өмет өстәүчеләргә башка караш хакимлек итә. Мисал өчен, Россия Фәннәр академия институтының ялган фәннәр һәм фәнни тикшеренүләрне фальсификациялаүгә каршы көрәш буенча комиссиясе вәкиле Александр Панчинның бу уңайдан фикере мондыйрак: «Галимнәр һәрвакытта да яхшы оратор түгел. Алар белгән, өйрәнгән мәгълүматны җиңел генә җиткерә дә алмаска мөмкин. Мистик тәгълиматларны пропагандалаган кешеләр ышандыра белә. Бу – аларның икмәге. Алар никадәр күбрәк ышандырсалар, шулкадәр күбрәк дан казаначак».

P.S. Язма нумерология һәм тарология кебек эзотерик юнәлешләрне күренеш буларак тасвирлау һәм алар белән таныштыру максатын күздә тотып язылды.



Форсаттан файдаланып, Резедадан Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең «тормыш матрицасы»н сораштык. Хөрмәтле шәхесебезнең тиздән туган көне җитәсен дә исәпкә алдык. Сурәттәге саннарның мәгънәсен һәм шәхеснең нинди энергиягә ия кеше булуын аңлатабыз.

Туган көн: 20.01.1937

•**20** – визит карточкасы:
кеше бу дөньяга: милләт, халык, ил хакына эшләргә; үз нәселен данларга, фамилиясен танытырга; гаилә кыйммәтләре турында җиткерергә, милли проектларда катнашырга дип туган. Еш кына мондый кеше башкаларга дәрес бирә. Аның бурычы – кешеләрнең аңын, дөньяга карашын үзгәртү.
Шәхес кармасы – «Гыйсъянчы» (Бунтарь) 15-20-5 программасы. Кеше гаиләсендәге башка әгъзалардан аерылып торырга мөмкин, бу шәхес ниндидер системага бик бәйле яисә, киресенчә, аны инкарь итә. «Бунтарь»ның бурычы – нәселгә яңалык алып килү.

•**1** – кешенең хәлиткеч энергиясе:
шәхескә бар җирдә һәм һәрвакыт беренче булырга кирәк. Аңа алдынгы позицияләрдә, беренче баскычта булу, идарә итү мөһим. Аның тормышында барысы да «тылсым таягы» ярдәме белән барлыкка килгәндәй тоелырга мөмкин. Бу аның узган тормышларында алынган көчле потенциалы, рухи өлгергәнлеге турында сөйли. Моңа 20-5-3, 21-7-4, 7-6-17 комбинацияләренең кабатлануы да ишарәли.

•4 тапкыр **7** энергиясе очрый. Бу кешегә алга бару, бер урында утырмау мөһим. Максатчанлык, карьера үсеше турында да әйтә.

•3 тапкыр **21** энергиясе очрый, өстәвенә финанслар зонасында да. Бу кешене дипломат буларак билгели. Аңа кешеләрне берләштерү, тынычлык һәм иминлек юлы белән бару мөһим.

Фәния
ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАР ЦИРКЫ

Өлкән буын хәтерлидер, мөгаен: элек башкалабызда Татар цирк төркеме оештырылып, ул үз вакытында Россия төбәкләрендә генә түгел, чит илләрдә дә менә дигән тамашалар күрсәтте. Андагы чыгышларның һәрберсе диярлек милли бизәкләргә төренгән иде. Бүген нәкъ җырдагы кебек уфтанырга гына кала: бу цирк кая китеп югалды икән? Ул ничек оешкан иде? Хәзер андый милли төркемне торгызырга мөмкинлекләр бармы? Гомумән, бу эш белән шөгыльләнергә теләк белдерәләрме?

Заманында Татар циркы төркеменең баш режиссеры булып эшләгән артист-иллюзионист, драматург, фокуслар җыентыгы, «Казан циркы һәм артистлары турында риваять» китабы авторы, «Күз буу – кара театр» студиясен оештыручы **Альберт ГАДЕЛШИН** белән без шул сорауларга җавап эзләдек.

:: Альберт Сөнгатович, аз гына тарихка кайтып, цирк ничек барлыкка килгән, дигән сорауга җавап бирик әле.
– Циркның тарихы атлы сугышчыларга бәйле. Урта гасырларда аларга сугышны алып бару өчен артык осталык кирәк булмаган. Чөнки ике яктан да гаскәр башлыклары кара-каршы сугышып, берсе озын сөңге белән дошманын аттан сугып төшергәч кенә ике гаскәр берберсенә ташланган. Шуннан кылыч белән чабу, үтереш башланган. Әмма вакыт узу белән җайдаклы сугышчылар өчен атта чабу, сугыш уеннарын үзләштерү мөһим бурычка әйләнә. Алар дошманнан сакланып калу өчен оста хәрәкәтләр ясарга тиеш булалар. Шулай итеп, Европа илләрендә атларда чабарга өйрәтә торган мәктәпләр ачылган. Беррәттән төрле күнегүләрне оста башкарып, халыкка да күрсәтә башлаганнар. Циркның тарихы әнә шул мәктәпләргә барып тоташа.

:: Татар кешесенең борын-борыннан атлар яратуын исәпкә алсак, димәк, бабаларыбызның циркка турыдан-туры катнашы булган дип әйтергә була.
– Бу хакта сүзне Сабантуйдан башласак, дөресрәк булыр. Бу бәйрәм, чыннан да, киң колачлы булып, халык циркы хезмәтен үтәгән. Сабантуйда аның күп кенә жанрлары бар: көрәшчеләр, ат чабышлары, баганага менү, бүрәнәдән ясалган «кәҗә»гә атлану, капчык сугышы, авыр герләр күтәрү һәм башка күп төрле уеннар, мәзәкләр, җыр-бию…

:: Сабантуй үзенә бер бәйрәм инде ул. Бу очракта бинасы булган стационар цирк турында сүз алып барсак, дөресрәк кебек. Башкалабыз кайчан циркълы була?
– Казанда беренче агач циркны бертуган Никитиннар 1890 елда төзи. Бу хакта документлар сакланган. Халык, агылып, тамаша карарга йөри башлый. Әлеге цирк 40 елдан артык хезмәт итә. Еллар уза, агач бина искерә. 1928 елда шул ук урынга яңа агач цирк төзелә. Аңа Татарстан АССРның сигезьеллыгына багышлап исем дә бирелә. Әмма ул халык теленә керми, бары тик кәгазьләрдә генә сакланып кала. Яңа бинага күп кенә үзгәрешләр кертелә, кыш өчен җылытылып, конюшня, грим бүлмәләре төзелә.

> Беренче татар цирк төркеме дә эшчәнлеген шушы агач бинада башлый. Беренче премьера 1956 елның февралендә була. Ул вакытта тәҗрибәле филармония артистларын оештыру күп чыгымнар сорамый. Кыска гына вакыт эчендә гади генә сценарий язылып, программа төзелә. Яңа гына иҗат ителгән цирк номеры күбрәк эстрада артистлары чыгышын хәтерләтә.

Шуңа күрә дә филармония артистлары беренче татар циркы төркемен төзүчеләр булып санала. Сәнгать җитәкчесе итеп Мөхәммәт Гыйсмәтуллин билгеләнә. Артистлар арасында гармунчы Гали ага Җәмлиханов, акробат Абдулла Хәбибуллин, аның партнеры, тормыш иптәше Тәскирә ханым, иллюзия-манипуляция остасы Габделхәй Мушинский, тамашаны алып баручы Фатих Колбарисов, акробат кыз Сания Гыйниятуллина, көрәшче баһадир Йосыф Рәфыйков, трапеция гимнасты Мансур Хәбибуллин була. Ни кызганыч, бинаның юкка чыгуы татар төркемен дә тулысынча тарката.

Альберт Гаделшинның шәхси архивыннан

:: Циркта икенче татар төркемен оештырган кешенең нәкъ менә сез икәнлеген белгәч, гаҗәбрәк тә тоела. Чөнки беренче тапкыр цирк бусагасын да армиягә киткәндә генә атлап кергәнсез.
– 1958 елда, армиягә киткәндә, мин Октябрь бәйрәменә багышланган цирк программасын карадым. Шунда бу тамашага гашыйк булдым. Хезмәт итеп кайтканда цирк ябылган иде инде. Театр училищесына укырга кердем, әмма аны тәмамларга мөмкинлек булмады. Горький исемендәге клубка килеп, хорда җырлый, туры килгәндә, концерт программаларын алып бара башладым. Драма коллективында спектакльләрдә уйнап, тәҗрибә тупладым. Халык театрларына режиссерлар әзерләүче икееллык курска укырга кердем. Укуымны тәмамлап, таныклык алып, шул клубта эшли башладым. Кышларын шәһәргә «Цирк – сәхнәдә» коллективы килеп, мәдәният сарайларында чыгыш ясый. Мин берсен дә калдырмыйча карап барам. Циркта чыгыш ясарга хыялланам. Сәбәбе дә бар: армиядә чакта курслар тәмамлап, медбрат булып эшләгән идем. Шунда яныма бер әрмән егете ияләште. Фокуслар өйрәтте. Әйтергә кирәк, андый нәрсәләргә кечкенәдән үзем дә һәвәс идем. Кайткач, тәҗрибәмне арттыра барып, концерт бригадаларында иллюзионист булып чыгыш ясый башладым. Аннан филармониягә эшкә кердем. Белем алырга кирәк иде. КДУның РТО бүлеген читтән торып тәмамладым. 1964 елда Татарстанда зур монументаль цирк төзү турында карар чыкты. Тәвәккәлләдем дә булачак циркның директоры Николай Панов янына киттем. Уртак тел табылды: төзелеп беткәч тә, баш администратор булып килерсең дип, эшкә чакырды. Шулвакыт беррәттән зур хыялым – татар циркы төркеме төзү турында да сөйләп аттым. Ризалашты. Цирк ачылуы 1967 елның көзендә безнең концерт бригадасы гастрольдә иде. Ташлап китеп булмый бит инде. Ачылышка кайтып җитә алмадым. Бик борчылдым. Директор да, син кайда югалдың, дип, упкәләп каршы алды. Шулай да, элемтәдә бул, дип тынычландырды. Әй, күңелле булган иде ул чакта. Халык гөж килә. Тамашасына караганда бинасын күрү өчен киләләр. Бер ел тирәсе вакыт үткәч, мине дә эшкә чакырдылар.

:: Сезнең төп хыялыгыз татар коллективын төзү бит инде. Теләктәшләр табылдымы?
– Тәҗрибәле өлкән артистлар белән киңәшеп, татар цирк коллективы төзүне үзебезгә төп бурыч итеп куйдык. Республика җитәкчеләре, безнең тәкъдимне хуплап, Союзгосциркка мөрәҗәгать иттеләр. 1969 елда икенче татар цирк студиясе ачылу турында карар чыкты. Афишалар бастырылып, радио, телевидение аша белдерүләр биругә, яшьләр агылып килде. Биш йөздән артык гариза кабул ителде. Шул исәптән үземнең гаризаны да теркәп, конкурс аша узып, кабул итү көне җитте. Союзгосциркның үзәк студиясе режиссерлары һәм өлкән артистлар катнашында жюри игълан ителде. Биш йөздән артык абитуриенттан өченче турга утыз кеше калдык. Ниһаять, ел буена барган киеренке хезмәт җимеше булып, 1970 елның 23 июнендә татар коллективы, ТАССРның 50 еллыгына багышлап, «Сабантуй» дип аталган зур бәйрәм чыгышы әзерләде. Ул вакытта бигрәк тә татар зыялылары арасында, менә безнең дә милли циркыбыз булды, дип әйтүчеләр күбәйде. Аларның сүзләрендә милли горурлык сизелә иде. Татар цирк коллективының беренче җитәкчесе Валерия Акинина-Хисаметдинова булды. Аны бик яратып «коллективның әнисе» дип йөрттеләр. Ул үзе дә төркемебез бердәм булсын өчен бөтен көчен куйды. Яңа номерлар, яңа программалар әзерләнде. Күп кенә чит илләрдә гастрольләрдә булдык. Иҗат уңышлары өчен Муса Җәлил исемендәге премия белән бүләкләндек. Коллективның аерым номерлары Америка, Япония, Бразилия, Германия һәм башка күп кенә илләрдә гастрольләрдә булып, дөньяда татар циркы барлыгын таныттылар.

> Кыска вакыт эчендә оешкан татар цирк коллективы, яшь булуына карамастан, йөзләгән совет цирклары белән бер рәткә басты. Коллективка Союзгосцирк системасында эшләүче профессиональ татар артистлары да кушылган иде.

Ни кызганыч, Валерия Николаевна лаеклы ялга киткәч, коллективта үзгәрешләр башланды. Манежда үзләрен тәҗрибәле оста дип хис итә башлаган артистлар «йолдыз чире» белән авырый башладылар. Күбесендә, коллективтан китеп, «конвейер»да эшләп, чит илләргә гастрольгә барырга омтылу теләге кабына башлады. Җитмәсә, үзебезнең дә тәҗрибә аз иде. Клоуннарның репертуары да отышлы түгел. Тамашачыларны көлдерү, аз гына булса да елмайта алу – бик катлаулы бурыч бит ул. Аптырагач, Союзгосцирк «конвейер»ыннан татарның берденбер цирк клоуны Хәсән Мусинны чакыртып алдылар. Әмма аның да репертуары бик искергән иде, ул аны, өлкән яшьтә булгангадыр инде, яңартырга теләмәде дә. Өстәвенә җитәкче дә алышынды. Ул үзе үк директор да, баш режиссер да булып килде. Миңа шапито директоры урынын тәкъдим иттеләр, янәсе, режиссерлыкка белемем җитми. Ризалашмыйча, филармониягә китеп бардым. Әмма, татар цирк коллективын төзүгә шулкадәр көч куеп та, ташлап китүем дөрес булдымы икән, дигән сорау мине гел бораулап торды. ГИТИСка укырга керү теләге башымнан чыкмады. Ниһаять, конкурстан үтеп, югары режиссерлар курсына тәкъдим ителдем. Укуны тәмамлагач, Ярославль циркына эшкә җибәрделәр. Өч ел үткәч, Татарстан өлкә комитеты җитәкчесе Мөдәррис Мусин мине эзләп табарга куша. Шулай итеп, мине Казан циркының баш режиссеры итеп күчерделәр.

Без татар төркеменең номерларын яңартырга тырышсак та, ул шактый көчсезләнгән иде инде. 19 ел эшләгәннән соң, 1988 елда бу төркем таркалды.

:: Бүген циркта милли бизәкләргә баетылган татар төркеме төзү чынбарлыкка туры киләме?
– Туры килә, әлбәттә. Моның өчен бары тик, үз эшенә тугры булып, янып-көеп йөри торган кеше генә кирәк. Талантлар җитәрлек бит бездә. Казан циркы каршында балалар циркы мәктәбен ачу турындагы фикерне дә мин тәкъдим иткән идем. 1996 елда ачылган мәктәп бүген дә эшләп килә. Мәктәптә тәрбияләнгән егермедән артык яшь артист Росгосцирка, Мәскәүдә Юрий Никулин исемендәге циркта эшли. Дөньяның иң популяр циркына әверелгән Америка «Дю Солей» циркы белән контракт төзүчеләр дә күп. Зур бүләкләргә ия булучылар да бар. Әмма, ни кызганыч, бүген Казан циркы килешүләр төзеп, төрле җирләрдән килгән коллективлар өчен чыгыш ясау урыны булып кына хезмәт итә.

:: Бәлки, бүгенге цирк сезнең кебек белгечләрнең киңәш-табышларын көтәдер?
– Андый үтенеч белән мөрәҗәгать иткәннәре юк. Элек сакчы янында циркта эшләгән ветераннарның исемлегe эленеп торды. Һәм без, документ күрсәтеп, бернинди каршылыксыз бинага үтә алдык. Элемтәбез нык иде. Хәзер исә андый мөмкинлекне дә юкка чыгардылар.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ҺӘР АВЫЛДА БЕР ФӘНИСӘ БУЛСА...

Авылдашлары әнә шулай ди. Кешеләрне бер учка җыя белә ул, башкаларны да ярдәмләшеп яшәргә өйрәтә. Үзе әйтмешли, бер сызгыруы җитә.

Арча районының Кәче авылында яшәүче 28 яшьлек Фәнисә Галәвиева белән кеше хәсрәте таныштырды безне. Күршеләренең йорты янып көлгә әйләнгәч, ул бөтен республиканы аякка бастырды. Бастырмый да мөмкин түгел. Кыш көне 9 кешелек гаилә урамда калды бит! Икенче мәртәбә янулары икән инде! Кайгы ялгыз гына йөрми. Ике атнадан Вәлиәхмәтовларның әниләре дә үлеп киткән. Тагын Фәнисәгә йөгерергә туры килгән. Дөрес, үзен мактаганны яратмый ул. «Авылдашларыма рәхмәт, алар сүземне тыңлый», – ди.

Күмәк эш тау күчерә, диләр. Күршеләре янгач, Фәнисә гел бер сүзне кабатлады: акчасы җыелса, йортын күтәреп бирәчәкбез. Шөкер, сүзләрендә торалар. Вәлиәхмәтовларга авылдашлары һәм якташлары гына түгел, бөтен республика булышты. Җыелган акчага төзелеш материаллары алып, авыл егетләре йортның диварын күтәреп куйган да инде. Бушлай. Хәзер түбәсен ябарга җыенып йөриләр икән.

Сер түгел, кеше кайгысын күрмәмешкә сабышып, хәлен кирәк чакта гына белергә ияләшеп киләбез. Кайгыны уртаклашса да, шатлыгыны күтәрә алмаучы туганнар да бар хәтта. Шөкер, чит кешенең хәсрәтен үзенеке иткән, бар җаны-тәне белән ярдәм күрсәтергә тырышып йөрүчеләр дә юк түгел. Фәнисә әнә шундый.

– Әби белән үстем мин. Бар эшкә ул өйрәтте. Кеше нинди гозер белән килмәсен, шундук хәл итеп бирәм. Кешегә дә үтенечемне бер генә әйтәм. Ир-ат холыклы икәнемне авылдашлар да белә, – ди ул. – Әтиемнең 3 бертуганы бар иде. Апабыз мәрхүм инде. Ә менә ике авыру абыебыз исән-сау. Аларны мин карыйм. Язмыш үземне дә сынады инде. Яшь әле син дип тормады, әбиемне, әтиемне, апаемны соңгы юлга озатырга туры килде. Кеше язмышына битараф кала алмыйм мин. Булдыра алганда, ничек ярдәм итмисең ди. Бер-береңә терәк булу кирәк.

Фәнисә терәк булуның ни икәнен яхшы белә. Гаиләсенә, күрше Илсөя апасына бик рәхмәтле ул. Үзе кеше мәшәкатьләре белән йөргәндә, ике авыру абыйсын нәкъ менә Илсөя апасы тәрбияләп тора. Аларның икесенә дә чит кеше ярдәме кирәк. Әбисенең «балаларымны ташлама» дигән әманәтен үтәр өчен, әтисенең төп йортына күченгән. Ире тимер эшләрендә оста. Теләүчегә йөреп эшли. Фәнисә үзе тирә-якта табын әзерләү белән танылган.

– Төн йокламыйча да эшлим. Эштән куркып торганым юк. Шушы яшемә ике йорт салдык инде без. Кирпеч тә өя беләм, измәсен дә болгатам. Җәбеп утырып булмый, тормыш итәсе бар. Кызыбыз үсеп килә. Тормышыбыз мул булсын дип тырышабыз, – ди Фәнисә. – Әле ярый әби аш-суга өйрәткән, дим. Кичтән шалтыратып, безгә ризык әзерлә дисәләр, төн йокламыйча пешереп чыгам. Бу эшне акчасыннан бигрәк, үзем яратканга башкарам. Кеше аш үткәрсә дә, туган көнен бәйрәм итсә дә, мине чакыра хәзер. Бөтен эшне өйдә эшләп барам. Токмачын кисеп куям, аш шулпасына кадәр кайнатып алып барам. Салатлар ясыйм, гөбәдия пешереп бирәм. Кайчак әзерне табыннарына тезеп кенә кайтам, кайвакыт ярдәм итеп, кунак итеп торуымны сорыйлар. Анысын да эшлим. Акчаны да күп сорамыйм. Бәрәкәте кирәк аның. Ризык бәясен капласа, эшләгәнем өчен бераз булса, миңа шул җитә.

Яшь булса да, Фәнисә бәхетнең ни икәнен аңлаган инде. Һәрхәлдә, үзе шулай ди. Бәхетне ул кеше рәхмәтендә күрә.

– Рәхмәт әйтүләре гүя канат куя миңа. Кеше хакыннан куркам. Миңа күчергән һәр акчага хисап ясыйм. Кешегә эшләгән яхшылыгым озак тормый, меңе белән әйләнеп кайта. Бу бәхет түгелмени! Һәр нәрсәне аңлый белергә кирәк, – ди ул. – Тормышта сынаулар күп күрсәм дә, язмышыма бик рәхмәтлемен. Әтиемнең туганнарын карый алганыма да сөенәм. Әби аларны миңа калдырып китте. Аның да рухы шаттыр! Яшәү, дөнья куу – бер хәл, әле бит безнең бакыйлыкка күчәсе бар. Анда буш кул белән барып булмый. Савапның артыгы булмас.

Вәлиәхмәтовларга ярдәм итәсегез килсә, Фәнисә Фәнис кызы Галәвиева исемендәге картага (Сбербанк) акча күчерә аласыз. Ул 89083496906 номерына беркетелгән.

БАЛА ХАКЫНА УЗГАН ГОМЕР

Ниләр генә күрми хатын-кыз! Башта тормышта үз юлын табар өчен тырышу-тырмашулар, күп мәртәбә алдану һәм югалтулар, аннары өметләрне чәлпәрәмә китергән эчкече ир. Әле шулар янында тимер рәшәткә артында үткәрелгән 2 ел гомер дә бар. Дөрес, Наташа артка борылып карамаска, боларның барысын да сызып атарга, онытырга тырыша. Бар уйлаганы – язмыш сынавына әверелгән авыру бала.

Наташа Пиговаева Арча районында яши. Исем-фамилиясе генә русча аның. «Миллэтем – чуаш, телем татарныкы», – ди үзе. Чистай районындагы балалар йортында тәрбияләнгән. Кулында балачак хатирәсе булган бер генә документы бар. Анда 48 ел элек Буа районында туганлыгы язылган. Әмма ул әти-әнисенең кем икәнен, аларның кайдалыгын әлегә кадәр ачыклый алмаган. Аның каравы бердәнбер кыз туганын эзләп тапкан. Марина да Чистайдагы ятимнәр йортында үскән. Тик алар моңа кадәр бер-берсенең барлыгын да белмәгән. Инде хәзер табышкач та, артык аралашмыйлар икән. Әмма үзен ялгыз тоймый Наташа. Янында буй җиткән улы, күршеләре бар.

– Чистайда урта белем алдым. Ятимнәр йортыннан Казанга укырга килдем. Ике елдан соң, эшкә урнаштым. Тулай тораклан бүлмә дә бирделәр. Инде үз тормышымны башлап җибәрдем дигәндә генә, эштән кыскартуга эләктем, – ди ул. – Иптәш кызым белән башка бер заводка урнаштык. Тик озак та үтмәде, дус кызым, өстенә панель төшеп, һәлак булды. Якын кешемне югалткач, мин дә эштән китеп бардым. Биектауга кайтып урнаштым.

Наташа монда төрле эштә эшли. Сыерын да сава, терлеген дә карый. Булачак ире белән дә шунда таныша ул. Озак та үтми, алар бергә яши башлыйлар һәм Арча районындагы Югары Оры авылына барып урнашалар.

– Иремне бик ошатып кияүгә чыккан идем. Әмма мин уйлаганча булмады. Хәмер белән дус булды. Салгач инде кул да күтәрергә күп сорамый иде. Түзәргә тырыштым. Ятимлек ачысын күргән кешегә үз гаиләсен коруның нинди зур бәхет икәнен белсәгез иде сез! Мин ул чакта язмышым шулдыр дип сабыр иттем, ялгыз каласым килмәде. Тормышның матур якларын күрергә тырыштым. Бер мәлне авырга узганымны белдем. Әмма аңы томаланган кешене бу гына туктата алмады. Шулай итеп, хастаханәгә барып эләктем, – дип искә ала Наташа.

Аның бик тә сабый сөясе килә. Табиблар баланы ярып ала. 6 айлык малай 900 граммлы булып туа. Әни дә, нәни дә яшәү өчен тырмашалар. Сөенеп, өйләренә кайтып керсәләр, ире тагын тавыш чыгара. Наташага кул күтәрүе – бер хәл, ир сабыйга да тынычлык күрсәтми. Җитмәсә, 8 ай чагында малайның күзләре күрмәгәне ачыклана. Кыскасы, йортта сабыйга да көн бетә.

– Ирем улымны биш яшенә кадәр кимсетте. Бер тавыш чыкканда, ни эшләгәнемне дә сизми калганмын, – дип сөйли Наташа. Полициягә үзе хәбәр бирә. Хатынны ике елга хөкем итәләр, әтисез калган малайны исә интернатка җибәрәләр.

Тизрәк улын күрү хыялы белән яшәгән Наташаны иреккә вакытыннан алда чыгаралар. Иң беренче эш итеп Димасын барып ала ул. Аннары алар кабат Арчага юл тота. Бар булган акчасына авылдан кечкенә йорт сатып алалар. Иске булса да, ярап тора ул. Җитмәсә, бер дигән күршеләр туры килә. Димага да, үзенә дә ярдәм итеп торалар.

Наташа бар гомерен улына багышлый. Малайның күзләре күрмәсә дә, аларны өзелмәс җепләр бәйли. Дима матур итеп җырлый. Төрле бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр дә яулый икән. Ике зур хыял белән яши ул. Диманың синтезаторлы буласы һәм Арчада фатир аласы килә. Арчага күченәсе килүнең сәбәбе дә бар: үзе кебек күрүдән мәхрүм калган кыз белән бергә буласы килә. Әлегә хыяллары тормышка ашмаса да, өметләре өзелмәгән. Хәзергә исә булганына риза булып яшәп яталар.

– Мин күршеләремә бик рәхмәтле. Итен, сөтен, йомыркасын бирәләр. Безне ашатып-эчертеп торалар. Йортым иске, идәннәрем суык булса да, зарлана алмыйм. Бүгенге көнемә чиксез рәхмәтлемен, – ди Наташа. – Улыма 18 яшь тулды. Язмышка да үпкәләмим инде күптән. Үз туганнарым булмаса да, ялгыз калмадым. Читләр дә үзеңнеке кебек якын була ала икән. Улым өчен дә җаным тыныч. Маңгай күзе күрмәү берни түгел, аның күңел күзләре бар. Алар бер дә алдамый!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

АЛСУ ГАЙНУЛЛИНА:

«ТЕАТР ҮЗ СҮЗЕН ӘЙТЕРГӘ ТИЕШ»

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Алсу ГАЙНУЛЛИНА сәхнәгә чыкса, залда ниндидер бер дулкын уза. Тамашачы ниндидер хикмәт көтәдер, күрәсең. Һәм бу табигый дә. Аның Гөлбануы, Гөлйөземе, Сәрби, Клеопатра, Шәмсегаяны, һәрбер роле төп фикерне әйтә килде. Шул ук хәл яңа гына сәхнәгә куелган «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр»дә дә кабатланды. Без аның белән театр һәм заман проблемалары һәм башка мәсьәләләр турында сөйләштек.

:: Театр ул...

– ...яшәү рәвеше. Театр ул – икенче гаиләбез һәм көндәлеге фикерне әйтү мөмкинлеге дә. Нинди генә заман килмәсен, театрда һич югы ым-ишарә белән булса да вазгыятькә карата фикерне әйтеп була. Минем өчен ул әнә шул ягы белән бигрәк тә кадерле.

:: Сез яшьли килеп кергән театр нинди иде һәм хәзер нинди?

– Рухы шул ук, кешеләре генә башка. Мин – Марсель Сәлимҗанов укучысы, ул алып керде мине бу дөньяга. Ул чакта биредә Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Рәшидә Җиһаншина, Вера Минкина, Галимә Ибраһимова, алар белән беррәттән данлыклы щепкинчылар эшли. Мин әнә шул зур гаиләгә барып кердем, алар белән күпме вакыйгалар кичердем. Искә төшерсәң, сөбханалла... Хәер, артка борылып карарга бик яратмыйм. Иң рәхәт чак – ул сабый чак. Анда әти-әни, абый-апалар сиңа җил дә тидермәгән, кайгырту кабырчыгында яшәткән. Ник дигәндә, мин төпчек, тугызынчы бала булып дөньяга килгәнмен. Менә шул кадерле балачакка еш әйләнеп кайтам. Аннан соң инде катлаулы вакытлар китә. Профессия сайлау, эшли башлау, гаилә кору, җыеп әйткәндә, тормыш арбасына җигелү. Анысы – яшәргә өйрәнү чоры. Гаилә тоту, иреңә ярау, баланы үстерү, эшләү, мөгамәлә кору. Дөрес, боларның барысы да үз җаена барды, катлаулыклар булмый тормый, әлбәттә, ләкин без аларны җиңеп яшибез.

:: Читтән караганда, балачактагы кадер-хөрмәт гомер буе барган кебек тоела. Сез – театрда кадерле актриса.

– Мин бу хакта еш уйланам. Балачакта адәм баласы нинди гаиләдә үсә, аның киләчәк тормышы да шул халәттә бара, күрәсең. Ата-ана үзләрендә яңа тормыш башланганны сизүгә, туачак баланы мәхәббәт белән көтсә, сабый тулы мәхәббәттә үссә, дөрес тәрбия алса, аның тормышы матур, тулы канлы булачак.

:: Сез берсеннән-берсе катлаулырак бик күп образлар тудыргансыз. Шулар арасында менә бу – чын героиня, татар хатын-кызының асылын ачып бирә дип кайсын атар идегез?

– Алар барысы да героинялар иде. «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендәге Йөзембикәне генә алыйк. Героиня түгел-мени?

:: Спектакль бит Әлмәндәр турында, Йөзембикә төп герой түгел.

– Аңа карап Йөзембикә истә калмыймыни? Аның мәхәббәте, мөлаем, тыйнак, зирәк булуы. Ярата да, юл да куя белә. «Татар хатыны нилләр күрми» спектаклендәге Гөлбануны алыйк. Әлбәттә, тормышы катлаулы... Ә идеаль героиня була аламы соң ул? Авырлыкларсыз кеше ныгый аламы?

:: Актрисага хас төп сыйфатлар нинди?

– Беренчедән, талант кирәк. Аннары үз эшеңне бернигә дә карамый ярату. Болар һәр һөнәргә кагыла. Мәсәлән, чәчтарашны, тырнак ясаучыларны гына алыйк. Кешене яратып пакьләүчеләр бит алар! Миңа калса, адәм баласы теге яки бу кәсепкә яралып туа. Аның күңелендә шул һөнәрнең нигезе ята. Аны үстерү өчен тормышта төрле мөмкинлекләр туа, сиңа бик күп тырышырга туры килә.

Еш кына: «Актриса булу турында хыялландыгызмы?» – дип сорыйлар. Юк, хыялланмадым. Мәктәптә әйбәт укыдым, әмма бер дәресне дә аерып куймый идем.

> Кеше бит мәктәптән планлаштыра, шул юнәлештә тырышыбрак укый. Миндә әнә шул нәрсә булмады. Менә хәзер, ник соң мин мәктәптә кем булам, кая барам дип бер дә уйланмадым икән, дим. Илле яшьләремдә мин бу сорауга җавап таптым. Әнием тугыз бала үстерде, үзен безне тәрбияләүгә багышлады. Мин хәзер, театр юлына кереп китмәсәм, әни кебек үземне гаиләгә багышлап, итәк тутырып бала үстергән булыр идем дип уйлыйм. Ихлас менә!

Алай да бер теләгем бар иде. Алтмышынчы елларда безнең гаилә Казанга күченде. Савиново бистәсендә төпләндек, ерак түгел туганнарыбыз да яши. Аларда телевизор бар иде. Без аларга телевизор тапшыруларын карарга йөри идек. Аның берсе – «Голубой огонек», аннары фигуралы шуу һәм хоккей. Менә бу тапшыруларны калдырмаска тырыша идек. Үзебезгә телевизор алгач, боларга татарча тапшырулар кушылды. Спектакль алдыннан диктор чыгып сөйләгәндә, шушы һөнәргә кызыгу туды. Әмма ул кадәр зур теләк түгел иде ул.

Көннәр үтә торды, сигезенче сыйныфны тәмамлар чак җитте. Шунда рус теле укытучысы, сиңа актриса булырга кирәк, диде. Мин аны колагым белән ишеттем, әмма күңелемә салып куймадым. Тугызынчы сыйныфта укый башладым. Концертларда катнашам, шигырьләр сөйлим, телевизор карыйм. Телевидение торган саен күбрәк әкияти дөнья кебек тоела. Диктор булсаң икән дигән теләк борын төртә, әмма үсеп китә алмый. Әмма насыйбы барыбер шул юл булган икән инде. Мине җитәкләп диярлек йөрттеләр. Мәктәптән иптәш кызларым драма түгәрәгенә алып киттеләр. Анда журналист, педагог Асия Юнысова «Беренче театр»ны куйган, шунда мин уйнаганмын. Режиссер Камил Саттаров шунда мине күргән дә, Урицкий мәдәният сараена чакырды, анда театр түгәрәгенә киттем. Шунда күреп алып, театр училищесына чакырдылар. Кабул иттеләр, әмма моңа әллә ни шатланмадым бугай. Чөнки актриса буласым килми, диктор буласым килә иде. Шунысы кызык: укуны тәмамлагач, диктор итеп чакырдылар, тик анда мин театр белән агуланган идем инде. Әмма театр юлына кереп китмәсәм, үземне һичшиксез гаиләгә генә багышлар идем.

:: Димәк, сез гаилә кешесе?

– Әлбәттә. Әмма театр тормышына кереп киткәч, гаилә кешесе генә булып булмый инде. Икесен бер дәрәҗәдә алып барырга кирәк. Минем өчен гаилә һәрвакыт беренче урында булды. Аннан соң гына театр.

:: Менә сез гаиләдә – дүрт артист, дүрт шәхес. Авыр түгелме?

– Юк, без – нормальный кешеләр. «Бзик» юк беребездә дә. Дөрес, тора-бара актерлык үз эшен итә, эмоцияләр чыга башлый. Аны контрольдә тотарга була. Тыныч булырга кирәк.

:: Гадәттә, ир дә, хатын да талантлы булса, ир ачылсын өчен хатын арткы планда кала, ир хакына талантын корбан итә. Сез урталыкны сайлый алгансыз. Моңа ничек ирешергә?

– Бер-береңне яратасың, хөрмәт итәсең икән, тормышта да, эштә дә ниндидер корбаннар кирәк булмый. Олы мәхәббәт булса, «яки мин, яки эш» дигән шартлар куелмый. Бер-береңне аңлыйсың, бер-береңә юл бирәсең, бер-береңне гафу итәсең. Мәхәббәт янында эгоизм яши алмый. Эгоизм гына талантны корбан итәргә сорый.

:: Улыгыз Искәндәр театр юлын сайлыйм дигәч, бер дә каршы килмәдегезме?

– Аны да бит Марсель Сәлимҗанов укытты. Ә Марсель Хәкимович Илдар белән мине балалары кебек якын күрә, хәтта гаилә проблемаларын җайларга ярдәм итә иде. Искәндәрне инде алар бәби чактан беләләр.

Мин бит аны театрга бик йөртмәдем. Чөнки алып килдеңме баланы театрга, аны инде карарга кирәк. Ә минем рольләр зур, сәхнәдән чыкмыйча эшләргә кирәк. Монда инде я уйныйсың, я бала карыйсың, икенең берсе. Андый чакта Искәндәрне әнием, туганнарым, каенанам, каенанамның туганнары, күршеләр карады. Без Вафирә Гыйзәтуллина, Рәшит Әхмәтҗанов, Роберт Миңнуллин, Зилә Сөнгатуллина белән бер йортта яшәдек. Менә алар караштым,

рәхмәт яусын. Гастрольләргә китсәк, бер-ике атналык кына булса, Искәндәрне калдырырга тырыштым, айлар буена чыгып китсәк, анда инде гаиләбез белән кузгала идек. Марсель абый исә Искәндәрне оныгы кебек якын күрә, ярдәм итә иде. Күрәсең, Искәндәр аларга «ачыла» торган булган, Марсель абый аның сәләтен безгә караганда иртәрәк шәйләгән иде. Без аны театр училищесын сайлар дип уйламадык та хәтта. Һәрхәлдә, мин ул хакта бөтенләй уйламадым. Ник дигәндә, Искәндәр драма түгәрәкләренә дә йөрмәде, театрга исә, әйткәнемчә, йөртмәскә тырыштым. Искәндәрнең теләген безгә Марсель абый җиткерде. Ике халык артистыннан берәр артист чыгар әле, ди. Баксаң, ул аларга, бигрәк тә Гөлнар апага уйнап күрсәтә торган булган икән. Шулай итеп Искәндәр дә Марсель Сәлимҗанов курсына эләкте. Туксанынчы еллар үзгәрешләре башланып, бер төркем яшьләрне чит илләрдә бизнес өлкәсендә укырга җибәрә башлагач, мин Искәндәргә, улым, чит илдә укырга теләгең юкмы, дип сорадым. Ул чакта Искәндәр беренче курсны тәмамлаган һәм театр белән агуланган иде инде.

:: Рольләре өчен әти-әнисеннән тәнкыйть «эләгә» идеме? Гомумән, бер-берегезнең эшен тәнкыйтьлисезме?

– Киңәш биргән булды, тәнкыйтьләгән булмады. Бигрәк тә мин. Гаилә әгъзалары бер сәхнәдә очраша икән, алар инде анда ир белән хатын да, бала белән ата да түгел. Ул – бөтенләй башка дөнья. Әлеге дөньяда катлаулы проблемалар да, җаныңны тарайтып кысып торган хәзерге вазгыять тә юкка чыга. Анда хәтта чир онытыла. Алар барысы да сәхнә читендә кала. Без Илдар белән бик күп спектакльләрдә сәхнә партнерлары булдык. Анда син образда һәм сиңа якын кешең карап тормый. Шулай да кайчак ул образ карашы белән түгел, Илдар карашы белән карап ала яки сулыш алуы образныкы түгел, Илдарныкы була. Аны шунда ук сизәсең һәм нәрсәдер дөрес булмады, ахры, дип уйлап куясың.

:: Сез иң күп уйнаган актриса дисәк, дөрес буламы?

– Әлбәттә! Мин бик күп уйнадым.

:: Үзегезне тулысынча ачылдым дип әйтә аласызмы?

– Җанкисәккәем, ничек ачылмаска инде?! Әлбәттә! Берсеннән-берсе катлаулы рольләр бирелде. Ролең катлы-катлы булса гына тамашачыга каравы кызыклы. Ә андый киңкырлы эш ул җиңел генә бирелми. Булды дигәне дә әле аның әллә булган, әллә юк. Башкарып чыккан эшеңнән гел ризасызлык кала. Шулай булырга тиеш инде ул.

:: «Мөһаҗирләр» спектаклендәге карчык ролегез әсәрдәге төп фикерне әйтә. Бер караганда, ул төп роль дә түгел иде, әмма бөтен барлыгы, җанга тигән сүзләре белән истә калды. Әлеге спектакль турында төрле сүз булды, тәнкыйте дә күп булды. Ә сезнең өчен ул нинди спектакль иде?

– Тәнкыйть ул – табигый нәрсә. Иҗат тәнкыйтьсез үсә алмый. Чөнки һәр кешенең әсәргә, андагы проблемаларга үз карашы. Режиссерны мин зур картиналар иҗат итүче рәссам белән тиңләштерәм. Ул да үзенең рәсемен ясый. Фәрит Бикчәнтәевнең – үз карашы. Аны кемдер кабул итә, кемдер кабул итми. Бу – табигый хәл. Әле бит моннан тыш та тәэсир итә торган көчләр бар. Болар – замана, спектакль куелган вакыттагы вакыйгалар. Аларга карата үз фикереңне әйтәсе килә, әмма еш кына әйтеп тә булмый. Туры әйткән туганына ярамый. Драматургия аша үз фикереңне әйтергә тырышуны олы хезмәт дип бәялим.

…Пароходка утырып киткән мөһаҗирләргә карап елыйсы килә бит! Бичаракайлар чит мәмләкәтләргә барып төшәләр, аларны анда көтәләрме соң?

Мин үзебезнең театрда чыккан бөтен спектакльләрне дә яратам. Ләкин бу сукыр мәхәббәт түгел! Беренчедән, биредә талантлы кешеләр иҗат итә. Театр сәнгатенең каймагы дияр идем. Ил буенча алсак та, дөнья күләмендә карасак та, талантлы режиссерлар бармак белән генә санарлык. Камал театрында исә Марсель Сәлимҗановтан соң шул рухны саклап килгән талантлы режиссер Фәрит Бикчәнтәев эшли. Галиәсгар Камал театрын җитәкләп бару – бик катлаулы эш, Алла ярдәм бирсен! Театр һәрвакыт үз сүзен әйтергә тиеш, драматургия аркылы, ишарә белән генә булса да. «Мөһаҗирләр»дә дә ул сүз әйтелгән!

:: Милли театрлар, бер караганда, чәчрәп тә чыга алмый инде. Без – тигез ритмда, артык шаукымга бирелмичә яшәүче халык.

– Ә ул – безнең саклану чарасы! Без – сабыр, иманлы, тыйнак һәм хәйләкәр халык, дип тә өстәр идем. Ә хәйлә – икенче гакыл ул.

:: Камал театрының яңа бинасы проекты расланды. Ул төзелеп, театр яңа җиргә күченгәч, аның эчтәлеге үзгәрәчәкме?

– Минемчә, мондагы эчтәлек тагын да зуррак масштаблар алачак. Былтыргы сезон репертуарын карагыз сез, бер-бер артлы нинди көчле спектакльләр чыгардык. Соңгысы – «Рәшә», аңа кадәр «Көл» булды. Спектакльдән соң, безнең театр – бик тә бәхетле, дип сөйләшеп тордык. Чөнки нигезе ныклы аның. Ә ул нигезне салучыларны, монда хезмәт итүчеләрне көчле рухлы илаһи затлар дип атар идем. Мин белгән чорны гына алсак та, шулай бит ул. Мин Марсель Сәлимҗанов эшләгән чорда килеп кердем. Театрда Празат Исәнбәт, Нәкый Исәнбәт, аннары Туфан Миңнуллин, Хәй Вахит, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев – режиссерлар һәм драматурглар эшләделәр. Аннары Фәрит Мәскәүдә укып кайтты. Марсель абый аны сөенеп каршы алды. Ул вафат булганнан соң, Фәрит: «Марсель абый кулы астында мин шундый рәхәт яшәдем. Нәрсә куярга теләдем, шуны куйдым. Ул миңа иҗатта тулы ирек бирде», – диде. Ул «Бичура», «Ромео һәм Джульетта»сы… Ә бит бу Марсель Хәкимович хәер-фатыйхасы белән эшләнде. Аны без аңламаган да булыр идек, Мәскәү тәнкыйтьчесе Поюровский, сирәк театрларда гына баш режиссер талантлы, яшь режиссерга юл куя, диде. Марсель абый, үзе турында уйламады, киләчәкне кайгыртты. Хәзер менә шул хәл кабатлана: Фәриткә ярдәмгә Айдар Җаббаров кайтты. Ә Айдар – Фәритнең шәкерте.

> Марсель абый театр баласы иде. Фәрит Бикчәнтәев тә театрда үсте. Мин бу очракта Наилә апага (Гәрәева. – **Ред.**) рәхмәтле. Ул баласын театрны яратырга өйрәткән. Шуңа күрә Фәрит һәрбер артист өчен борчыла, һәрберебезне ярата. Булганның кадерен белеп яшик.

:: Алсу апа, сез – яшьли прима дигән иң зур бәяне алган актриса. Ә сездән соң шундый зур талантлар бармы?

– Бар! Нишләп булмасын?.. Һәр артист үзенчә талантлы. Һәрбер чорның үз геройлары, үз героинялары. Аларны халык билгели. Мин яшьләрне күзәтәм, алар бик талантлы. Вакыт күрсәтер, уңышлар телик аларга!

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

(ХИКӘЯ)

ИМӘН САПЛЫ КӨРӘК

Безнең келәттә бер сәер генә ядкарь бар. Нәсел-нәсәпнең берәр укымышлысы дөнья куудан туктап, озын картлыгын ничек үткәрергә белми аптыраганда, шәҗәрә китабын язарга алынса, ул ядкарь турында һичшиксез «дөнья бәһасе торырлык иде» дип искә алачак. Чынлыкта исә, аның базар хакы да әллә ни юкюгын, хәерче базарына куйсаң, сатучыны җәлләп яисә кул хәтере җир эшенә сусаган берәрсе кызыгып алса гына. Морза бабайлардан калган асылташ кашлы йөзек тә, Бохарада суфи шәехләрдә белем алганда, кулга төшергән сирәк кулъязма китап та түгел ул, ә гап-гади имән саплы көрәк. Миңнегали бабай көрәге ул.

Кояшлы көнне келәткә керсәң, калай түбә ярыгыннан төшкән яктылык көлтәсендә елык-елык итеп торган көрәк сабына, көрәк очының яңа туган айга охшап җемелдәп торган пычагына игътибар итми калып булмый. Күргән саен хатирәләр яңара да, Миңнегали бабайның: «Тиясе булма!» – дигән сүзе бөтен ачу-үпкәсе, әрнү-рәнҗеше белән искә төшеп куырылып киләсең.

Аның кап уртадан бераз гына кыегаеп киткән сабы буеннан-буена ачык көрән төсле майлы буяу белән буяп лаклаган кебек ялтырап тора. Чынлыкта Миңнегали бабайның балавызга мангандай тыгызланып каешланган каты кулында шулай шомарып беткән ул. Бабакай җир казыйсы яки бәрәңге утыртасы-аласы булса, бакча башына килгәч, иң элек җиргә көрәген кадап куя. Аннан гәзиткә төргән махоркасын колак артыннан алып кабыза да бер-ике суыргач, көрәк сабының башына төртеп сүндереп, калганын янә урынына кыстыра. Шуннан тәмәке төтенендә ысланган төкреге белән ике учын да чамалап кына юешләтеп, авыз эченнән үзе генә белгән «бисмилла»сын кабатлап, коралын кулына ала. Һәм көрәк шуннан үзе эшләп китә диярсең, артыннан өлгереп кенә барасы. Бәрәңге утыртканда, бабакай бразнаны үзе сала. Шушындый җаваплы эшне дөнья күрмәгән, эш рәтен белмәгән, ата малын әрәм-шәрәм итәргә генә торган малайларга тапшырамы соң инде?! Әнә, карап тормасаң, орлык бәрәңгесен дә ояга ничек кенә ыргыталар. Иманнарын ак күмәчкә алыштырган шәһәрләрендә тротуардан үтеп барышлый чүп савытына алма чүбе ташлап китәләрмени? Ул бәрәңгеләрне каен утынының көлендә генә әвәләп, май кояшы җылысына куеп, бәләкәй сагаладымыни ул? Шыткысы борын төрткәнен тилмереп көтте. Ә бу имансызлар шул шыткыны сындырып, уңышны харап итәргә генә торалар. Бәрәңге утырту рәтен дә белмәгән башлары белән кемне-кемне – Миңнегали картны өйрәткән булалар бит әле: имештер, кышлык бәрәңгене сатып алырга да була, бакча тутырып утыртмасаң да ярый. «Мин үлгәч, утыртмассыз, кычкырып, ачка үлмәсәгез», – дип кенә җибәрә шәһәр гидайларына аталары. Бразнаны чыгып беткәч, бабакай көрәгенә дөнья күчәренә таянгандай, билен турайтмый гына бөтен гәүдәсе белән салынып таянып тора. Таянырга көрәге булганда, беренче бразнада үзе торачак әле ул дип, эчке бер тантана белән арттагыларны күзәтә. Шундый вакытта аның тамак кырганы ишетелсә, арттагы өч көрәк тә, бәрәңге салып барган чиләкләр дә ничектер үтә-күренмәлегә әйләнгәндәй була. Югыйсә бразнаны да аталарының арткы аяк эзенә туры китереп сызып, орлыкның да һәркайсын тавык йомыркасы кебек кадерләп кенә ояга салып баралар да соң!

– Ашаганда, кашыгыгыз да шулай авыз кырыеннан гына үтеп-сүтеп йөримe сезнең? – ди бабакай. Ул шаярта дип шаяртырга ярамаганны өлкән буын белә дә, ә менә оныкларның телен тыеп кара.

– Синең көрәгең үзе эшли торган бугай ул, бабакай, – дип, салпы ягына салам гына кыстырмакчы иде иң бәләкәй онык Илһам да. – Миңа бирсәң, мин дә нәкъ шулай эшләр идем.

– Син башта әниеңнең итәгеннән төш тә көрәкне үзең яса, аннан көрәк сиңа эшли башлар, – дигән җавап Илһамның маңгаена гына килеп ябышты. Алай да ял иткән арада терекөмеш малай көрәкне тикшереп карарга булып, ялтырап торган көрәк сабына орынган гына иде, бу ихатада күзләре бөтен җирдә булган бабакайның тавышы гүя күктән иңде:

– Тиясе булма!!!

Әле дә – әнә шулай келәт түбәсендә аркылы тактага яткырып куелган килеш тә тияргә ярамый ул көрәккә. Ядкарь булганы өчен генә түгел, Миңнегали бабай исән чагында ук аның эш коралларына якын килергә рөхсәт юк иде. Көрәгенә бигрәк тә. Кая ул тию, бабакай аңа озаграк карап торганны күрсә дә, кымырҗый башлый, ләкин әле сүз әйтми, тешсез уртлары белән яңакларын чәйнәгәне генә сизелә. Шуннан бик кирәкле эшен исенә төшергәндәй, коралына таба кырын карый-карый, кырт-кырт басып, җәһәт-җәһәт кенә атлап киткән була да биш-алты адым атлауга нәрсәсендер исенә төшергән кеше кебек юырттып кына кире урап килә. «Мин монда, малай актыгы, барысын да күреп торам, уеңа да кертәсе булма этлегеңне» дигәндәй, катлап-катлап, тамак кырып куя. Бу инде җитди кисәтү дигән сүз, инде моннан соң да көрәк тирәсендә буталсаң, аяусыз җәзадан үзеңә генә түгел, шушындый «әрәмтакмак»ны бу дөньяга тудырган әткәң белән әнкәңә дә өлеш мулдан чыгачак.

Ә Илһам ут белән уйнарга ярата иде. Бәрәңге утыртканда да, алганда да, гөнаһ шомлыгы, берәр мәрәкә китереп чыгармый калмый, яз көне бер тапкыр, көз көне бер тапкыр Миңнегали карт көрәге белән һаваны телеп-телеп, яшендәй ялтыратып, оныгын шәһәргә куа иде.

Еллар үтеп, бабакайның бәрәңгелек тә хәле калмаганда да, бакча башында көрәгенә таянып торырлыгы була торган иде. Соңгы елны Илһам кайтышлый ук трактор сөйләште дә бабакае чыгып, тәртипләрен урнаштыра башлаганчы, бәрәңгесен утырттырып та куйды. Тракторга каршы көрәге белән никадәр генә кизәнсә дә, бабакай бирелергә мәҗбүр булды.

Миңнегали карт исә үз закуны бозылганны күреп, йөрәк өянәге тотканчы тузынды. Юк, күтәрә алмады ул бу башбаштаклыкны. Шуннан соң җәй буена бәрәңге бакчасына чыгып та карамады. Ә көз көне бәрәңгеләр алыр вакыт җиткәндә, аның закуннарыннан башка гына яши алган дөньяга үпкәләп, шулай да көрәгенә берәүне дә, бигрәк тә Илһамны якын китермәскә васыять әйтеп, бакыйлыкка күчте. Нәкъ шушы оныгында үзенең киребеткән, үҗәт холкы икәнен тәки аңламады карт. Вафатыннан соң авылга кайтып, ихатаны гөл итеп яшәгән оныгы да Илһам булды аның.

Хәзер инде ул ядкарь әле булса бабакайны искә төшереп, келәт түбәсендә эленеп тора. Әле булса аңа кагылырга ярамый. Берәрсе дуамалланып тотына калса, бөтен нәсел-нәсәп дигәндәй аягүрә баса да: «Бабакай рухын кыймылдатмагыз, ачуландырмагыз», – дип көяләнә башлый. Әллә курку, әллә сагыну шунда, аңламассың…

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

2 КВИТАНЦИЯ
КҮЧЕРМӘСЕН
БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

Әз-мәз мәзәк

Яңа елны яңа фатирда чибәр кыз белән каршыладым. Эльдар Рязановка рәхмәт.

* * *

– Синекенә нигә яшь?
– Быел мәктәпкә барачак.
– О! Уза гомер...
– Әйе, физрук булып эшкә урнашты.

* * *

– Кадерлем, матур бизәндемме, кареле.
– Якынча 15–20 лайк җыярлык.

* * *

– Ну ничек? Теге кыз белән таныша алдыңмы?
– Әйе. Ә теге төшкән тешне барыбер алдырасы идем инде.

* * *

Зоопаркка бардым әле бүген. Үземне күрсәттем, башкаларны карадым.

ГЫЙНВАР УЛ...

Безнең якларда иң салкын ай.

Туйлар һәм никахлар иң аз үткәрелә торган вакыт. Бөтен туйларның 5 проценттан әзрәге генә гыйнварга туры килә.

1885 елга кадәр рус телендә «январь» һәм «генварь» сүзләре бертигез йөрештә булган.

Борынгы рус телендә мондый атамалары билгеле: просинец, перезимье, лютовей, трескун, ломонос.

Атамасы Римның вакыт һәм ишек алласы Янус (Ianuarius) исеменә бәйле, дип фаразлыйлар.

Күп халыкларда бу ай бөтенләй башкача яңгырый. Әйтик, финнарда ул tammikuu – «имән ае» дигәнне аңлата.

Татарга «гыйнвар» сүзе Византиядән килгән булырга мөмкин. Анда бу ай «генуарис» дип йөртелгән.



Беләсең килсә...

1 «Джентльмены удачи» фильмында төшкән әлеге артистның әтисе заманында Татар обкомының беренче секретаре булган.
а) Мурат Насыйров;
б) Раднэр Моратов;
в) Ратмир Әхияров.

2 Үсемлекләрнең кислород эшләп чыгару процессы ничек дип атала?
а) фитофтороз;
б) фотосинтез;
в) оргсинтез.

3 Кар бөртегенең ничә почы бар?
а) 6;
б) 8;
в) 12.

4 Статистика буенча иң зур буйлы ирләр кайсы илдә яши?
а) Алжир;
б) Бразилия;
в) Нидерланд.

Җаваплар: 1. б); 2. б); 3. а); 4. в).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: яманат, ступор, Оса,Татарстан, ау, яки, Рамилә, балдак, иярчен, җыр, Кыям, елан, Пешт, кар, Кев, По, әнә, Уел, Лев, Ришат, еш, Илаһи, ре, ия, Нарзан, аммиак, томшык.

Вертикаль: Тарпищев, Лир, Пеле, Тимерҗанова, чын, Һидаят, мотороллер, Кәрия, Усс, пани, имам, Напата, керәшен, Аударыш, арасы, Тирән, ят, Утар, Ярдәм, ке, Елена, Киркоров.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 204

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+